

## Кереш сүз

Бу дөньяда кеше дигәнең барысы да бертөрле түгел бит. Була бик оста, җор телле, кыю кешеләр. Ә кемдер булдыра алганын да башкалар алдында я сөйләргә, я күрсәтергә кыенсына, ояла. Сүзем, Аллаһыдан бирелгән әзме-күпме сәләте булып та, үз казанында гына кайнап яшәгән үзешчән шигырь чыгаручылар турында. Авылдашларым арасында андыйлар байтак икән ич ! Кайсысы белән генә сөйләшсәң дә, “үзем өчен генә язгалыйм” яки “күңел түремдәге хисләремне кәгазь битләренә төшерәм” дип, тыйнак кына җаваплыйлар алар.

Җырчы күңеле тулганда җырлый. Гармунчы, гармунда уйнап, күңелен бушата. Көй язучы күңелендәге кичерешләрен синең җаныңны, үзәгеңне мең кат өзәрлек көй тудыра. Шагыйрь хисләрен шигырь юлларына сала.

Әйе, нәкъ шулай. Безнекеләр һич кенә дә шагыйрь түгелләр ( җыентыкка кергән берничәсеннән кала), шагыйрь дип аталуга өмет тә багламыйлар, алар бары тик шигырьчеләр. Ә шулай да алар күңеле хисле-тойгылы, сүзләре хәтерле-гыйбрәтле, башкаларга да кирәкле. Шигырьчеләребез иҗаты барлык яктан да камил, ягъни бер кимчелексез дип әйтеп булмый. Әмма аларның язганы чын йөрәктән, ихлас күңелдән туган, язылган.

Адәм баласының күңелендә шундый халәт була: әле кычкырып җырлыйсы, әле үксеп елыйсы килә. Менә шундый минутларда кемдер кулына каләм ала, ә кемдер башка берәүнең шигырь юлларын укып, күңеленә тынычлык, җанына рәхәтлек таба. Менә шулай гади генә, тыйнак кына шигырь барлыкка килә.

Ә мин, кулларына каләм алган авылдашларымның хис-тойгылы, уй-кичерешле сүзләр тезмәләрен, язмаларын барлап, туплап, җыентык итеп чыгарырга булдым. Китапның исемен дә бик гади атадым: “Каләм алдым кулыма...”

Кереш сүземне мәктәптә укыганда ук шигырьләр язарга һәвәс, бик тә сәләтле укучым Марат Гыймадиев сүзләре белән тәмамлыйм. Бер әдәби кичәдә шигърияткә карата үз фикерләрен Марат менә ничек белдергән иде: “Шигырь язарга кечкенәдән яраттым, ләкин мин аны киләчәк һөнәрем дип кабул итмим. Шигърият – иң шифалы нәрсә. Ул бер генә күңел кылларына да кагылмый калмыйдыр. Чөнки ул – иң самими, эчкерсез хисләр җимеше. Кулларына каләм алганннарга илһам, матур-матур иҗат җимешләре теләп калам. Йөрәкләрдә шигырь уты сүнмәсен, сүрелмәсен!”

### Шигърият

Шигърият!
Серләремне сиңа ачып салам,
Син бит миңа һәрчак бик кирәк.
Син булмасаң, нәрсә эшләр иде,
Дулкынланып типкән бу йөрәк.

*( Гөлзадә Әхтәмова)*



## ФӘЙЗЕЛХАК ГЫЙЛЬФАН УЛЫ ХӨСНЕТДИНОВ
**(1916 – 2005)**

Бондюг районы Бәзәкә авылында 1916 елда туган. Бәзәкә мәктәбендә белем алганнан соң, 1936 елда Алабуга китапханәчеләр техникумында, аннары укытучылар институтында белем ала. Әмма укуын төгәлли ала алмый, хәрби хезмәткә алына. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк катнаша. Аңа әсирлек газапларының ачысын да татырга туры килә. 1946 елда туган якларына әйләнеп кайта. Башта Абалач авылында, аннары Бәзәкә мәктәбендә укытучы булып эшли. Лаеклы ялга чыкканчы, немец теле, тарих фәннәрен укыта. Фәйзелхак абый - Бөек Ватан сугышы һәм мәгариф ветераны.

Шигърият өлкәсендә дә мөгаллим матур-матур шигъри тәлгәшләрен укучыларына бүләк итте. Аның шигырьләрен укучысы Сәлахетдин Таҗиев “Ядкарь булып яшьләргә” исемле китап итеп чыгарды. Китаптагы берничә шигыренә көй дә язылган.

## ТЫНЫЧ БУЛСЫН ДӨНЬЯЛАР

Изге Ватан өчен көрәш бара,
Кара төтен баскан күк йөзен.
Дошман атакасын кайтарабыз
Иртә таңнан алып без бүген.
Пушкалардан бөркеп ут чәчелә,
Җир тетери залпларыннан.
Кемнәр-кемне дигән кискен чакта
Дуслар килде шәрык ягыннан.
Дошман атакасы кайтарылды,
Танклары яна кыр тулып.
Фашистларның корган планнары
Күккә очты тагын көл булып.
Тормышыбыз гөрләп чәчәк аткан
Шундый рәхәт, тыныч заманда.
Канга сеңеп калган сугыш кыры
Төшкә керә әле һаман да.
Сугыш беткәч күпме сулар акты,
Сыкрый әле алган яралар.
Көтә һаман ирен тол хатыннар,
Улын көтә газиз аналар.
Без кичергән сугыш газапларын
Күрмәсеннәр безнең балалар.
Барлык йөрәкләрдә бердәм теләк –
Имин генә булсын дөньялар!

1979 ел.

## ЯДКАРЬ БУЛЫП ЯШЬЛӘРГӘ

Һәр язда без Җиңү бәйрәмендә
Җыелабыз изге урынга.
Һәйкәлләргә килеп баш иябез,
Үлгәннәргә сугыш кырында.
Хәтердә бит сугыш дәһшәтләре,
Үлемнәрне күргән мең юллар.
Йөрәкләргә мәңге җуелмаслык
Яра салган авыр ул еллар.
Без бәхетле, чөнки язмыш безгә
Бүләк итте ике гомерне:
Аның берсе узды сугышларда,
Икенчесе – бүген түгелме?
Дошманнарга каршы көрәшләрдә
Бәйсезлеген илнең яуладык.
Гасырларга күчәр безнең исем –
Туар буыннарга юл салдык.

Дөньялар бит тыныч, тормыш рәхәт,
Тик яшәргә, бары яшәргә.
Ветераннар гына азаялар –
Ядкарь булып җирдә яшәргә.
1987 ел.

**ЮКСЫНУ**

Мәктәп торган биек тауга карап
Ник юксына икән күңелем?
Балаларга тәүге белем биреп
Узгангамы шунда гомерем?
Көзләр җиткән саен сиңа киләм,
Нигез ташың гына калса да.
Ни булган соң тауда басып торсаң,
Истәлеккә генә булса да?
Ак тәрәзә, зәңгәр капкаларың
Әйләнгәнгәдер инде күмергә.
Балаларың сукмак өзмәс иде
Исән торсаң синнән гомергә.
Бакчаларың кыргый урман булган,
Коймаларың сүтеп алганнар.
Каеннарың тора башын иеп,
Гүя алар ятим калганнар.
Каеннарга карап басып торам,
Фикер йөри артта еракта.
Күз алдымнан уза барысы, кинәт
Җиз кыңгырау чыңлый колакта.
Яңа мәктәп – матур һәм зур бина,
Булып торам анда еш кына.
Әллә инде бергә картайганга,
Күңел никтер тегесен юксына...
1988 ел.

**КЛАСС ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ничә тапкыр инде егет булдым.
Ничә тапкыр килде балачак.
Менә шулай алмашына килә
Күңел язым инде ничә кат.
Нәни дуслар белән дүртенчедән
Унынчыга  кадәр үсәмен.
Үскән дуслар китә, ә мин исә
Кабат дүртенчегә төшәмен.
Шулай итеп, егет булгач кына,
Тагын кайта балачакларым.
Сабый белән сабый дигән кебек,
Балаларча яши башладым.
Чиратлашкан җәйләр, көзләр кебек,
Кабатлана тора гел шулай.
Чигә чәчләремә чал керсә дә,
Алар белән күңел – шук малай.
Класс җитәкчесе менә шулай,
Чәче агарса да башында.
Бала белән бала була белә,
Егет белән егет каршында.
1975 ел.

**СӘЛАМ СИҢА, АБАЛАЧ!**

Еллар узып, юлым күмелсә дә,
Искә алсам яшьлек елларын.
Ерак-еракларадан әйләнә дә,
Сиңа кайта күңел юлларым.
Кояш чыккан чакта тауга менсәм,
Синең якларны да күзлимен.
Ничә еллар инде газетадан
Синең исемеңне эзлимен.
Тугайларың, көмеш чишмәләрең
Күз алдымда әле ал таңың.
Язның айлы тыныч кичләрендә
Тальян тарта иде Солтаның.
Изге мәктәп, бинаң, укучылар
Төшләремә әле керәләр.
Шат күңелле таныш балаларың
Бакчасында гүя йөгерәләр.
Күпер чыгам инешеңә карап,
Колагымда яңгырый шул сәгать.
Су буенда, имеш, алачыкта
Тимер суга чың-чың Сибагать.
Колхозыңда уңган егетләрнең
Яңа төзешләр төзиме?
Шәйхетдиннәр, Ризван, Кәшифләрең
Һаман шунда эшләп йөриме?
Мәктәп ерак иде, тау башында,
Ул урыннан инде күчтеме?
Без барында яңа утыртылган
Мансур наратлары үстеме?
Оныткандыр димә, онытмадым,
Сәлам сиңа, сәлам, Абалач!
Таныш юлчың булып бер узармын
Сандугачың килгәч, яз булгач.

1977 ел.

**ҖЫРЫ КАЛДЫ**

*Мәктәп елларында яратып укыткан укучым,*
*шагыйрь Марсель Гыймазетдиновның якты истәлегенә.*

Күтәрелеп күккә балкытты ул
Авылы офыкларын ялгызы.
Көтмәгәндә кинәт юкка чыкты
Авылыбызның якты йолдызы.
Йолдыз атыла да юкка чыга
Якты эз калдырып һавада.
Шагыйрь юкка чыкса, җыры кала,
Мәңге ядкарь булып дөньяда.

1993 ел.

**СИНЕ ЭЗЛИМ**

*Тормыш иптәшем Зәйтүнә Гәлиеваның якты истәлегенә.*

Сине эзлим чыклы чәчәкләрдән
Алсуланып таңнар атканда.
Сине эзлим төнбоеклы күлдән,
Тын офыкта шәфәкъ батканда.
Сине эзлим күктә йолдызлардан,
Җемелдиләр, гүя көләсең.
Кайсы синдер алар арасында,
Шуны эзлим, килә беләсем.
Сине эзлим акчарлаклар очкан
Дәрья буендагы камыштан.
Йөрәк әрнеп сыкрый, тынгы тапмый
Юксынудан, кайгы-сагыштан.
Сине эзлим бакчаларга чыгып,
Син утырткан гөлләр үскәннәр.
Чәчәкләрен күргәч искә төшә,
Бергә матур гомер иткәннәр.
Сине эзлим күктән, җирдән, судан,
Тик таба алмыйм, кайда, кайда син?
Көзге яфрак кебек саргаермын,
Таба алмасам һаман сине мин.

1999 ел.

**ЕГЕТ БЕЛӘН БАБАЙ**

- Нигә мөшкел, әллә начармы эшең?
- Начар, бабай, күрсәтә күреш тешем.

Көндез дими, кич дими һәм төн дими,
Тәүлегенә бер көлергә дә бирми.
Ашау кая, йөгерә салкын, эссесе.
Сызлый башлый аскысы һәм өскесе.
Бер даруның аңа файдасы тимәс,
Үләм, бабай, бирче, зинһар, бер киңәш.

- Эшләгәннең эше, улым, эш икән,

Менә врач куйган тешләр теш икән.
Йөгерми һич аңар салкын, эссесе,
Сызламыйлар аскысы да өскесе.
Сызлый калса, шул секундта аласың,
Сау-сәламәт буласың да каласың.
Рәхәтләндем ничә еллар, кара аны,
Син дә шул врачка барып кара әле!

1989 ел.



**МАРСЕЛЬ ГЫЙЛЬФАН УЛЫ ГЫЙМАЗЕТДИНОВ**
**(1943 – 1993)**

Марсель Гыймазетдинов 1943 елда Бондюг районы Бәзәкә авылында колхозчы гаиләсендә туган. Мәктәптә Марсель тырыш, зиһенле, фәннәрне җиңел үзләштерүче, чаңгыда иң оста йөрүче була. Педагогия институтында укый, мөгаллимлек һөнәрен ала. Районыбыз авылларында укытучы, директор, соңрак берничә колхозда партоешма секретаре һәм колхоз рәисе булып эшли.

Марсель Гыймазетдинов – җир кешесе, ул иген игә, икмәк үстерә, ярты гомере басу, кырларды үтә. Ә кичен, тир түгеп кайтканнан соң, кулына каләм ала, газаплы да, ләззәтле дә шөгыль – иҗат эшенә керешә. Үзенең бар сәләтен ул халыкка багышлый. Аның өч шигырь китабы дөнья күрде, дистәдән артык шигырьләренә көй языла. Аларны танылган артистларыбыз яратып башкара. Әйе, аның шигырьләре безне яшьнәп яшәргә өнди, җырлары күңелләрне назлый, нурга баета.

Марсель Гыймазетдинов – Татарстан журналистлар берлеге әгъзасе, Республиканың иң күренекле, иң танылган шәхесләре тупланган “Татар энциклопедик сүзлек” кә кертелгән (1992 ел), Егор Уткин исемендәге премиянең беренче лауреаты.

## ТУГАН АВЫЛЫМ - БӘЗӘКӘМ.

*Владимир Мироваев көе*

Басуларда - башак җыры,
Тургай моңы кырларында.
Зифа буйлы сылуларың
Уйный йөрәк кылларында.

Кушымта:
Әй, Бәзәкәм, Бәзәкәм,
Языңны көтеп алам.
Тирәк, камыш, каен моңын
Йөрәк җырыма салам.

Иген игә егет-кызың,
"Кара алтын" таба илгә,
Шатланып туя алмыйм
Туганга мин Бәзәкәмдә.

Кушымта:
Әй, Бәзәкәм, Бәзәкәм,
Языңны көтеп алам.
Тирәк, камыш, каен моңын
Йөрәк җырыма салам.

## САУМЫ ТУГАН ҖИРЕМ.

Саулармы сез, туган як кырлары!..
Кайтам сезгә, кайтам кайгысыз.
Изге җирсез – туган яктан башка
Яши ала, әйтче, кайсыгыз.

Исәнмесез, яшел тугайларым,
Атлар көткән иркен болыннар?
Һаман сездә балачактагыдай,
Чабып йөри икән колыннар.

Ни хәлләрдә, авыл агайлары,
Исәнмесез, әби-апалар.
Туып-үскән җирен ташлаганнар
Саргаешып кире кайталар.

Саулармы сез, туган-тумачалар,
Исәнмесез, күрше-күләннәр!
Туганякларына ашкындылар
Чит җирләрдә яшәп үлгәннәр.

Ә мин кайтам, нык-нык басып кайтам,
Сине сагынып, яшьли торган җир.
Син гомергә яшә, анам кебек
Иң кадерле, садә, туган җир...

**САГЫШЛАРЫМ ТУГАН ЯКТА**

Туган якны кем сагынмый, кем юксынмый,
Шул якларга өзелеп карап, кем үксенми.
Көн дә кайтам уйларымда туган якка,
Моңнарымны көйгә салам синең хакта.

Кайтыгыз, дип пышылдыйлар
Хәтта үләннәр.
Туган якка барыбер кайта
Читтә йөргәннәр.

Сагыш утларында янам, туган ягым,
Синең турда җырлар җырлыйм менә тагын.
Йөрәк җырларымны илтсен сиңа җилләр,
Сагындыра икән, дуслар, туган җирләр.

Кайтыгыз, дип пышылдыйлар
Хәтта үләннәр.
Туган якка барыбер кайта
Читтә йөргәннәр.

Таралганбыз дөнья буйлап бәхет эзләп,
Җыйналышыйк, көтә безне туган төбәк.
Тик бәхетле була кеше туган якта –
Аңладым мин чит җирләрдә шушы хакта.

Сагышларга, сагнуларга,
Дуслар, түзмәдем.
Кайтып киләм, кабул итсә,
Туган җирләрем.

**ӘЙЛӘНЕП КАЙТ ӘЛЕ АВЫЛГА.**

Юксынам-дисең син, нигә соң ?
Гомерең узмаган бит әле.
Туган як кырларын сагынып,
Әйләнеп авылга кайт әле.

Саф чишмә сулары, һавасы,
Тугае, болыны, урманы.
Кочаклап алырлар үзеңне,
Шулардан кадерле җир бармы?

Күзләрең ямансу, боеклар,
Алар да авылны сагына.
Кайгырма, моңайма, юксынма,
Әйләнеп кайт кына авылга.

**БУРАЗНАЛАР, ИГЕН КЫРЛАРЫМ.**

Урманнарым мамык шәлен япкан,
Киң кырларда ап-ак юрганнар.
Шул кырлардан тәүге тапкыр бабам,
Атам, анам озын юл алган.

Басуларда иген шаулап үсә,
Шул кырлардан илһам, көч алам.
Тугайларым, сыр-сыр буразналар,
Сездән башка, юк, һич тора лмам.

Буразналар сыздым,
Бергә тезсәң,
Экваторны ничә әйләнер? –
Шул кырлардан, шул басудан башка
Күңелем буш минем нигәдер.

Кар астында минем буразналар
Әле изрәп йоклап яталар.
Озакламас, бар җиһан уяныр,
Иркен кырлар чәчәк атарлар.

Буразналар сөттәй пар чыгарыр,
Уҗымнарым дәррәү калкырлар.
Киң кырларны кочып үбәм, сөям
Һәм сөенәм – минем халкым бар.

Буразнада тапкан мине анам,
Кендек әби булган Җир-ана.
Җирдә тудым,
Тормыш юлым минем
Шул буразналардан башлана.

Китәсем юк сездән аерылып,
Ишетәсезме, басу-кырларым!
Гомеремне сезгә багышладым,
Сезгә булсын туар җырларым.

**ИГЕНЧЕГӘ.**

Чыгам да кырларга, сокланам:
Җыр җырлый күкләрдә тургайлар.
Һич бетмәс көч бирә, дәрт өсти
Басулар, урманнар, тугайлар.

Чыгам да кырларга, сокланам,
Башаклар тирбәлә саф җилдә.
Игенче, горурлан, хезмәтең, –
Иң бөек, иң даһи бу җирдә.

Чыгам да кырларга, уйланам:
Игенче, син изге, хикмәтле.
Туган ил сүзенә тиң сүзләр:
Тынычлык, игенче, икмәктер...

**ӘНКӘЕМНЕҢ АК ШӘЛЕ.**

Ак мамыктан әнкәм шәл бәйләде,

Челтәр-челтәр итеп читләрен.
Әйтерсең лә шулай бәйләгән ул
Ак шәл итеп йөрәк хисләрен.

Һәр элмәге гомер юлларыдай
Сызылып ята ап-ак шәлендә.
Төшләремә керә иңнәренә
Мамык шәлен салган хәлендә.

Әнкәемнең шәлен, әнкәемнең төсен
Саклыйм һаман күңел түрендә.
Сандыгында ап-ак шәле булган
Килен булып төшкән көнендә.

Яшь чактан ук ап-ак шәл ябынган,
Күңелкәе саф, пакь булганга.
Сандыгыннан челтәр шәлен алам,
Сагынудан күңелем тулганда.

## ТӘРӘЗӘДӘ НИЛӘР БАР ?

Төнге тынлык. Биш катлы йорт.
Тәрәзәләрдә ут яна.
Шатлык тулы бер тәрәздән
Җыр тарала дөньяга.

Бер тәрәзәдән оран сала
Яңа туган нарасый.
Якты көнгә күз салгандай,
Утка текәлгән сабый.

Бер тәрәзәдә кайгы уты –
Куя кеше дәньяны...
Тәрәзәләр нидер сөйли,
Тик аңлыйбызмы аны?..

Тәрәзәләрдә якты утлар –
Уйлар уйларны сүтә:
Кемдер килә, кемдер китә,
Ә яшәү дәвам итә.

## ТУГАН ҖИРНЕҢ КИТМӘС КОШЛАРЫ БЕЗ

Чәчәкле җәй үтте,
Моңсу көзләр җитте –
Очар кошлар китте тезелеп.
Һаваларда очкан,
Зәңгәр күкне кочкан
Кошлар кебек идек без элек.

Очар кошлар очсын,
Зәңгәр күкне кочсын –
Ә без калыйк туган төбәктә.
Туган җирнең яме –
Яшәешнең тәме,
Тамыр җәйгән безнең йөрәктә.

Яшел язлар җирдә,
Сагыну моңы җилдә –
Киткән кошлар кайта ашкынып.
Гел яшисе килә,
Бер яшьнисе килә –
Җанга тула бәхет ташкыны.

Язгы күкрәү кебек,
Яздай карыйк көлеп –
Эреп аксын салкын кышлары.
Без – җилкенеп очкан,
Зәңгәр күкне кочкан,
Туган җирнең китмәс кошлары,
Яз ясаучы китмәс кошлары.



**ФӘНИЯ КИРАМЕТДИН КЫЗЫ ШАКИРОВА**
**(1939 – 2015)**

Фәния Шакирова 1939 елны Бондюг районы Бәзәкә авылында колхозчы гаиләсендә туа. Әтисе Бөек Ватан сугышында һәлак була. 1953 елны 7 нче классны тәмамлый. Тормышлары авыр булу сәбәпле, алга таба укуын дәвам итә алмый, колхозда эшли башлый.

Туган ягын, халкын ярату, яудан кайтмаган әтисен сагыну хисләре, уй-кичерешләре, шигъри хиссият булып кәгазьгә төшә. Шигырьләре озак еллар район газетасында басылып килә. 1997 елда “Очар кошым” дигән китабы дөнья күрә. Байтак шигырьләренә Псәй авылының һәвәскәр композиторы Зиннур Мөхәмәтдинов көйләр яза. Фәния апаның күңеле һәрчак җыр-моңга тартыла. Сәхнәләрдә искиткеч матур җырлавы белән ул авылдашларының күңеленә татар җырларының назын-ләззәтен җиткерә алды.

Фәния Шакирова – Егор Уткин исемендәге премия лауреаты.

**ТУГАН АВЫЛЫМ.**

Әнкәм чит җирләрдә түгел,
Үз авылымда мине тудырган.
Челтер чишмәләрнең суын эчеп,
Инешендә битем юдырган.

Язмыш мине тудырган да,
Туган җиремдә калдырды.
Салкын кышы чыныктырды,
Җәйге кызуы яндырды.

Ташларына бастым яланаяк,
Тауларына мендем, үрмәләдем.
Бәхетләр дә күрдем, кайгылар да –
Үз халкымнан җәбер күрмәдем.

**БӘХЕТЛЕ БУЛЫР ИДЕМ.**

Мин бәхетле булыр идем
Дусларымның күңлен күрсәм,
Кайгыларын-сагышларын
Уртак итеп бүлә алсам.

Мин бәхетле булыр идем
Егылганнарны торгызсам.

Юксылларның әрнүләрен
Басар өчен дәва тапсам.

Мин бәхетле булыр идем
Халкым өчен хезмәт итсәм.
Шигырем белән илемә
Һәм җиремә ярдәм итсәм.

Мин бәхетле булыр идем...

## КҮҢЕЛКӘЕМ ЯШЬ МИНЕМ.

Гомер узды, картаелды, диләр,
Ә мин әле һаман ашыкмыйм.
Олыгайсам да күңелем яшь сыман,
Шигърияткә, җырга гашыйкмын.

Еллар узды, күпме сулар акты,
Бүген уйлыйм әле үткәнне.
Сизмичә дә, күрмичә дә калдым
Картлыгыма килеп җиткәнне.

Бу күңелкәй нигә картаймый икән
Үткән юлы авыр булса да?
Күңелләрнең яшен белеп булмый
Чәчләреңә бәсләр кунса да.

## ОЧАР КОШЫМ.

*Марсель Гыймазетдинов*
*истәлегенә багышлыйм.*

Очар кошым очты-китте, тоталмадым.
Очар кошка китмә, диеп әйтә алмадым.

Очар кошым ерак китте, кайта алмас.
Бүтән кошчык очар кошка тиң булмас.

Очар кошны уңнан көтмим, сулдан көтмим.
Бәхет миңа кире кайтмас, өмет итмим.

Очар кошым, нигә инде очып киттең,
Нигә соң син безне шулай ятим иттең?..

## ӘНКӘЕМНЕҢ СҮЗЛӘРЕ.

Килче минем яннарыма,
Утыр әле син, балам.
Тормыш юллары катлаулы
Синең өчен мин янам.

Кешеләргә кайгы килсә,
Әйтә күрче татлы сүз.
Әгәр сиңа хәвеф килсә
Тешләреңне кысып түз.

Масайма син бәхет иңсә,
Сөйлә уйлап сүзеңне.
Сөенечеңне уртаклаш

Һәм каралтма йөзеңне.

Аккан судай гомер уза,
Истә әнкәм йөзләре.
Хәтеремнән һич җуелмый
Әнкәемнең сүзләре.

## МӘҢГЕГӘ КИЛМӘДЕҢ.

Дошманнар урынсыз
Йөрәкне телгәләр.
Дусларың күп булса
Кайгыңны бүлгәләр.

Авырлык килгәндә
Суз ярдәм кулыңны.
Матурла, әй, кеше,
Барачак юлыңны.

Бирәүгә килә ул
Кайгылар иртәрәк.
Кемгәдер килә ул
Картаеп китәрәк.

Ярдәмчел бул, кеше,
Начарлык уйлама.
Мәңгегә килмәдең
Бу фани дөньяга.

## КАРА МИЛӘШ.

***Урал Рәшитов көе.***

Өй янындагы бакчага
Иркәм утыртты миләш.
Кайгыларга бирешмә, дип
Бирә ул миңа киңәш.

Кара миләш, кара миләш,
Бирә ул миңа киңәш.

Һәр ел саен кара миләш
Ак чәчәккә күмелә.
Кара миләшләргә карап
Үзәккәем өзелә.

Кара миләш, кара миләш,
Бирә ул миңа киңәш.

Өй янында кара миләш
Ядкарь, истәлек төсе.
Кайгым бик ачы булса да
Кара миләшем төче.

Кара миләш, кара миләш,
Бирә ул миңа киңәш.

## ИКЕ ЧИШМӘ.
(шаян көйгә)

Бәзәкәдә ике чишмә -
Баллы чишмә, Зур чишмә.
Көн дә кил, иркәм, чишмәгә,
Колонка суын эчмә.

Кичен суга килерсең, дип
Мин өзелеп көтәмен.
Битләреңнән үбәрмен, дип
Әле өмет итәмен.

Сихәтледер чишмә суы,
Кил, су эчәрбез, иркәм.
Үпкәләүләрең гел бетәр
Иренеңнән бер упсәм.

Алма-апельсиннар кайткан
Авылым кибетенә.
Бир кулыңны, сиңа чыгыйм
Бәзәкә егетенә.



## ЗӨФӘР ХӘМӘТ УЛЫ ГЫЙМАДИЕВ
## (1942 – 2016)

Зөфәр Гыймадиев 1942 елда Бондюг районы Бәзәкә авылында колхозчы гаиләсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлап, автомәктәптә, автотранспорт техникумында укый. Гомере буе Менделеевск АТПсында эшли, зур коллективны җитәкли. Тырышлыгы, намуслылыгы белән генераль директор дәрәҗәсенә күтәрелә, “Татарстанның атказанган автотранспорт хезмәткәре” дигән мактаулы исемгә лаек була.

Хезмәте тынгысыз булуга карамастан, күңелендә, йөрәгендә йөрткән хис-кичерешләрне ак кәгазь битләренә төшерергә дә вакыт таба. Шигырьләре район газетасында даими басылып чыктылар. “Баллы чишмә” шигыренә Алабуга каласында яшәүче үзешчән композитор Владимир Мироваев көй язды.

## КАЙТАМ ӘЛЕ ТУГАН АВЫЛГА.

Кайтам әле туган якларыма,
Эчим әле чишмә суларын.
Сызгырып бер үтим әле,
Бәбкә куган инеш юлларын

Инеш буендагы тал тирәкләр,
Кая сезнең сылу чагыгыз?
Кая безнең матур Пинәрдә
Балык тотып йөргән чагыбыз?

Туган якның матур болыннарын,
Җырлап үтәсем килә.
Яңа чапкан печән өсләрендә,
Яллар итәсем килә.

Булмас инде беркайчан да,

Хыялларым шулай калырлар.
Болыннарым, чабар печәннәрем,
Су астында инде калдылар.

Ә шулай да, кайтам әле,
Туган якка, туган авылга.
Туган туфрак мине тарта,
Мәңгелеккә шунда калырга.

## ИХ, ДУСКАЕМ!

Их, дускаем, җырлыйк әле,
Былбыллардан калышмыйк.
Сагышка бирелеп китеп,
Кайгыларга салышмыйк.

Их, дускаем, уйныйк әле,
Тальян гармуннар тартып.
Күңелләрне ачыйк әле,
Туган авылга кайтып.

Эчик әле чишмә суын,
Җиз савытка тутырып.
Бераз яллар итик әле,
Тау буена утырып.

Күл өстендә пар аккошлар
Канатларын кагына.
Сагышларым алып кайтты
Мине туган авылга.

## УЙЛАНУ.

Су буенда чирәмлектә
Ялгыз уйлап утырам.
Үтә гомер, картаябыз,
74не тутырам.

Күз алдыма китерәмен
Балачагым елларын.
Еракка даны таралган
Бәзәкә болыннарын.

Ничек инде онытасың
Печән чапкан чакларны.
Сызылып таңнар аткан чакта
Кешнәп чапкан атларны.

Бата-чума сазлыгында
Аз чапмадык күгәнен.
Сазлык диеп тә тормадык,
Шунда салдык күрәнен.

Тамак кибеп әлсерәгәч,
Суны эчтек сазлыктан.
Күрше күлгә дә бармадык
Вакытыбыз азлыктан.

Хәзер инде бүтән вакыт
Печән үсә кырларда.
Чалгы белән дә чапмыйлар,
Ишетелми җырлар да.

Үзгәртеп корабыз диеп
Болгаттылар заманны.
Үзгәрделәр кешеләр дә,
Белми дусны, туганны.

Ә бит кирәк уйланырга,
Кеше гомере бик кыска.
Иман белән яшик, дуслар,
Үтмәсен гомер бушка.

## БӘЗӘКӘ БОЛЫННАРЫ.

(Түбән Кама ГЭСы төзелү
уңаеннан үпкәбез)

Киләм дә тау итәгенә,
Күз саламын еракка.
Бер карыймын акчарлакка,
Бер карыймын аръякка.

Уйларымны сизгән кебек,
Акчарлагым килә яныма.
Болыннарны сагынып кайттым,
Яшьлегемә, туган ягыма.

Су өсте тулы акчарлак,
Кайда яшел аланнар?
Кайда күлләр, кайда урман,
Кайда кызыл баланнар?

Нигә соң кошлар сайрамый,
Кая алар киттеләр?
Киттеләр алар кайтмаска,
Безне ятим иттеләр.

Болыннарны су бастырып,
Түрәләр, нишләдегез?
Табигатьне тар-мар итеп,
Зур зыян эшләдегез.

Аннан-моннан гына уйлап,
Зур эшләр башкарасыз.
Сүзләр эштән аерыла,
Без калабыз чарасыз.

Әйтер идем - җитте сезгә,
Күп инде болгаттыгыз.
Күктә болыт кумагыз сез,
Җиргә әйләнеп кайтыгыз.

**БАЛЛЫ ЧИШМӘ**
*В. Мироваев көе.*

Очраштырды безне язмыш
Баллы чишмә буенда.
Су эчәргә килгән идек
Җәйге Сабан туенда.

Кушымта:
Эх, дускаем, кил әле,
Баллы чишмә буена.
Таллар да сине сагына,
Син генә гел уемда.

Урамнардан җырлап үттем
Авылым йоклап ятканда.
Саубуллаштык синең белән
Сызылып таңнар атканда.

Сагынып кайттым авылыма,
Төштем чишмә буена.
Таллар белән сөйләшәмен,
Ә син һаман уемда.

Ага чишмә сулары,
Тал тамырлары аша.
Сагынуларымны җиткерәм
Шушы җырларым аша.

**ӨМЕТЕҢНЕ ӨЗМӘ.**

Өметеңне өзмә, дустым,
Бирелмә сагышларга.
Эчеңдәге хәсрәтләрне,
Сиздермә танышларга.

Сөендермә дошманнарны,
Бетте бу димәсеннәр.
Гомер әле өзелмәгән,
Хәзергә көлмәсеннәр.

Җәлләмә үткән гомерне,
Ялгышлары булганга.
Үкенмә, дустым, үкенмә,
Бу дөньяга туганга.

Бәхетне юлга сипмиләр,
Кибеттә дә сатмыйлар.
Бәхетне эзләп табалар,
Аны көтеп ятмыйлар.

Өметеңне өзмә дустым,
Шатлык сиңа киләчәк.
Көтеп алган бәхет кошың,
"Син бәхетле"- диячәк.

## ЯЛ ЙОРТЫНДА.
(ярым шаяру)

Су буендагы талларым,
Нигә сез шаулашасыз?
Ял йортындагы дусларым,
Бигрәк тиз аңлашасыз.

Читтән генә карап торам,
Шундый матур парларга.
Сокланып туя алмыйсың,
Бәхетле дус-ярларга.

Барысы да парлы-парлы,
Бергәләшеп килгәннәр.
Киемнең дә матурларын,
Иң яхшысын кигәннәр.

Үкенеп бетә алмыймын,
Бер ялгызым килгәнгә.
Тиңләр идем мин үземне,
Ялгыз үскән имәнгә.

Ялгыз имән корый диләр,
Белмим инде нишләргә.
Парлашырга дип уйласам,
Хатын керә төшләргә.

Алла бирсә, киләсе елга,
Хатынны алып киләм,
Көнләшүләрем дә бетәр,
Ялгыз имән мин, димәм.

## АК ЧӘЧӘКЛӘР.

Май аенда аткан ак чәчәкләр
Күзләремнең явын алалар.
Сандугачның матур сайраулары
Сагышларга мине салалар.

Әйт, сандугач, гүзәл кошым,
Каян килә сиңа моң?
Мин дә шулай сайрар идем,
Булдыра алмыйм, нишлим соң?

Ак чәчкәләргә карыйм да,
Күңелем йомшарып китә.
Сабыр итәм, сине көтәм,
Яшь гомер шулай үтә.



**ӘНВӘР ХӘМӘТ УЛЫ ЗИННАТУЛЛИН**
**(1948-2012)**

1948 елда Бондюг районы Бәзәкә авылында колхозчы гаиләсендә туа. Мәктәптә укыганда ук теле йөгерек, сүзе тапкыр була аның. Мондый сыйфатларын күреп, Әнвәрне мәктәпнең стена газетасын чыгару буенча җаваплы итеп куялар. Менә шул елларда ук аның шигырьләр язуга хирыслыгы ачыла. Һәр яңа шигырен кичәләрдә үзе дә, иптәшләре дә укый. Шигырьләре районыбыз һәм республиканың “Яшь ленинчы” газетасында да басылалар.

Мәктәпне бетергәч, автомәктәптә укый, армия сафларына алына. Солдат хезмәтен кояшлы Төрекмәнстанда үтә. Бу елларда абыйсы белән хатларны да бер-берсенә шигъри юллар белән язышалар алар. Әнвәрнең туган як, әти-әнисе, гаиләсенә, мәхәббәткә багышланган шигырьләре сагыну, наз һәм ямьгә, нечкә хисләргә төрелеп язылган. Аларны уку күңелгә җиңеллек, җанга рәхәтлек бирә.

**Исәнмесез!**

Исәнмесез. Йөз чөереп йөрү кешелекме?
Сәлам биреп уз син кешегә!
Ачык йөзе, җылы сүзе белән
Җирдә кеше зур да, көчле дә.
Исәнмесез! Күрешә материклар,
Якынлаша җирнең уллары;
Шиңмәсенгә җирдә булган гөлләр,
Сүнмәсенгә кояш нурлары.
Исәнмесез! Туганлаша илләр
Ярдәмләшеп яшәр өченгә,
Исәнмесез! Кояш нуры белән
Тормыш яме иңгән бу сүзгә!

**Төрекмәнстан**

якты кояш иле!
Нур балкышы, кошлар сайравы.
Барысы рәхәт, ләкин бернәрсә дә
Алыштырмас Иделем ярларын.
Хурламыйм мин якты, гөлләр иле –
Төрекмәнстан, гөнаһ хурлау сине.
Оҗмахлардан качып кайтырмын мин
Зурлап, сагынып туган җиркәемне.
Йөрәк белән, тамырларда кайнар
Тибеш белән аккан каным да.
Җаным белән, бар барлыгым белән
Аерылмагач туган ягымнан.
Нигә шунда барыр юлларымда
Җәннәт ишекләре ачылмый.
Мин һаман да канатланып-очып
Туган туфрагыма кайтырмын!
Кичер мине, гүзәл Төрекмәнстан,
Мин яшәмим синдә, тик янам.
Дәрьяларың бик тә ярсу синең,
Иделкәем минем – үз анам!!!

**Кыш.**
Дөнья ап – ак . Агачларга
Бәсләр кунган.
Суык агай тәрәзләргә
Сүрәт уйган.
Кыекларда күгәрченнәр
Йон күпертеп
Утыралар муеннарын
Эчкә кертеп.
Чыпчык – чытлык посып ята
Саламлыкта .
Салкын ага киртә куя
Шаянлыкка.
Кешеләрнең сулышыннан
Пар бөркелә ,
Йөри алар һәммәсе дә
Җәһәт кенә.
Колак салсаң - әллә кайда
Йөргән кеше
Шыгырт – шыгырт яныңнан ук
Үтә төсле.
Вакыт-вакыт бүрәнәләр
Чатнап куя,
Әйтерсең, кыш кылган эшен
Раслап куя.
Алсу йөзле шат күңелле
Шук балалар
“Куян атып” карга батып
Тау шуалар.
Боз өстендә арлы-бирле
Йөгерешеп
Малай-шалай шар уйната
Янып-пешеп.
Салкын булсын, үлми кеше
Аңа карап.
Тик үз йөрәк салкыныңнан
Өшү харап.
(“Ялкын”журналында  конкурста катнашкан шигырь.1965 ел.)

**Башкаемны иям.**
Зәңгәр күзләреңә бу кадәрле
Ялкын кайдан туган?
Карашыңа кеше сүзләренә
Сыймас назлар сыйган...
Шулкадәрле төбәп карамачы –
Уңайсызлык тоям...
Олы сөю янган күзләргә мин
Лаек түгел сыман...
Яннарыма килеп баскан чакта
Кояш рәттән кебек.
Шуңадыр ла кыен иркәләргә
Чәчләреңнән үбеп...
Карашларың белән син минеке,
Әйтмәсәң дә сизәм...
Уйларымда синең күкрәгеңә
Башкаемны иям!..

**Йокысыз төн.**
Бер күз сирпеп алдың – шул да җиткән,
Күпме кирәк юләр күңелгә,
Шул да җиткән... туар көнгә кабат
Синең белән барып керергә.
Шул да җиткән...йөз өметле уйлап
Мең күзаллар өчен кересен.
Сөя белмәсен дә икән кеше!
Башкалардан гына сөелсен...
Акыл, акыл! Мондый сүзләреңне
Бу йөрәккә нигә сөйләргә!?
Кеше бөек! Кеше матур! Горур!
Онытылып сөя белгәндә.

**Көзге уйлар.**
Авазлары күкне моңга күмгән,
Кошлар китә... туган җирләрдән;
Һай, бу туган җирдән аерылулар
Мирас булып калган кемнәрдән?!
Япь-яшь имәннәрнең яфракларын
Җилләр йолкып илгә тарата...
Яфраклардай туган җирләреннән
Аерылганны тормыш саргайта.
Киткәннәрне туган туфрагыннан
Кызганам мин...авыр күңелгә...
Тик мин горур һәм шат, күзем ачкан,
Аунап үскән туган җиремдә!

**Киек казлар китә...**

Кыйгак-кыйгак...
киек казлар китә,
Киек казлар китә тезелеп.
Пилоткамны салып сәлам бирәм
Чын,
көнләшеп калам сүрелеп.
-Дускайларым, хөр-ирекле кошлар,
Бишегем аша минем үтсәгез,
Сәламләгез әткәм-әнкәемне,
Сөйгәнемне,
Ил солдатын якын күрегез:
Сәламләгез!
Ишетәсезме,әй, канатлы дуслар.
Ишетәсезме солдат авазын?
Мин әйтергә телим йөрәгемнең
Сагыш утларында кайнавын...
Җиткерергә телим хезмәтемдә
Сынатмавым,
намус белән хезмәт иткәнем.
Хат-хәбәрне дуслар-туганнардан
Һәрвакытта зарыгып көткәнем.
Сау булыгыз, һай, кайгысыз дуслар,
Армый-талмый гына очыгыз
Аерылмагыз! Аерылу – кайгы.
Уртак малны күмәк тотыгыз:
чын күңелдән сөйли

дустыгыз...

Киләчәккә зур өметләр белән
Бергә-бергә очу-омтылу –
Олы бәхет!
... Ә аерылуда – кайгы-сагыш,
Кара уйлар сазына йотылу...

**Яз җыры.**
Җир йөзендә гөрләвекләр җыры,
Һаваlардан сибелә тургай моңы,
Ак каеннар әнә, бөре ача,
Урамнарда шат көлүләр арта.
Һай, яз җиле, бигрәк шаян инде,
Яшь кызларның итәкләрен ача,
Карны ертып умырзая калка,
Җиргә,дуслар, матурлыклар кайта,
Эх, җырлыйсы иде шул хакта!



## ГАБДЕЛӘЗӘЛ ӘХМӘДИША УЛЫ ФӘЙРУШИН
## (1931-2000)

Габделәзәл Фәйрушин 1931елда Бондюг районы Бәзәкә авылында колхозчы гаиләсендә туа. Җиде сыйныфны туган авылында бетерә, 10 еллык белемне Бондюг мәктәбендә ала. Алабугада укытучылар институтын тәмамлап, берничә ел үзебезнең район мәктәпләрендә укытучы булып эшли.

Калган бөтен гомерен Яшел Үзән районы Карауҗа авылында яши, мәктәптә укытучы, озак еллар директор булып эшли. “Татарстанның атказанган укытучысы” дигән мактаулы исемгә лаек була.

Туган ягын, авылын сагынып, еш кайта. Инеш, әрәмә, Кама буйларында йөри, балачак елларын искә төшереп, күңелендә кадерле хатирәләрне яңарта. Шундый тәасирле мизгелләр аны шигырьләр язарга этәрә, чын ялны, ләззәтне шушы мавыгуы аша таба.

**БӘЗӘКӘМ - ЧУЛМАНЫМ.**

Тауның башында Бәзәкәм,
Итәгендә Чулманым.
Чулманымның саф суында
Коенамын, чумамын.

Синнән читтә үтә гомер,
И Бәзәкәм, Чулманым.
Сине уйлап алсу таңда
Сагышларга чумамын.

Авылымны сагынганга,
Ел да бер кайтып китәм
Дуслар белән Чулманымның
Балыгын авыз итәм

Киң Иделдә дә таныймын
Чулманымның бозларын.
Киң илемдә дә таныймын
Авылымның кызларын.

Кайткан саен тәрбиялим

Әти-әни каберен.
Гомрем читтә үткәч, беләм
Туган төбәк кадерен.

## КАЙТАМ ӘЛЕ СИҢА.

Тәүге ярым сиңа кайтыр өчен,
Өч кенә омтылмадым.
"Онытты ул!" - димә, рәнҗи күрмә!
Һич кенә онытмадым.

Агымсуда әгәр агып килсәм,
Тотып алырсың микән?
Сиңа атап әгәр җыр җырласам,
Отып калырсың микән?

Хатлар язам сиңа сагынганга,
Дәфтәремне тутырып.
Хатым барса әгәр иренмичә
Укырсыңмы утырып?

Җитәр микән белмим, җитмәс микән,
Талым читән үрергә?
Кайтам әле сиңа, һич югында
Сине читтән күрергә.

## РӘХМӘТ ӘТИ-ӘНИГӘ.

Җир әйләнеп чыкмасам да,
Күп йөрдем тирә-юньдә.
Алай да мин бәхетсез дип,
Зарланыйммы? Ә нигә?
Аяклар бүләк иткәннәр
Рәхмәт әти-әнигә!

Чит илләрне күрмәсәм дә,
Күрдем якты дөньяны.
Алай да мин бәхетсез дип,
Зарланыйммы? Ә нигә?
Күзләрне бүләк иткәннәр
Рәхмәт әти-әнигә!

Миллионер ук булмасам да,
Ризык табам үземә.
Алай да мин бәхетсез дип,
Зарланыйммы? Ә нигә?
Көч-куәт бүләк иткәннәр
Рәхмәт әти-әнигә!

Тәхеттә утырмасам да,
Хезмәт итәр урын бар.
Алай да мин бәхетсез дип,
Зарланыйммы? Ә нигә?
Зиһен дә бүләк иткәннәр
Рәхмәт әти-әнигә!

Сиксән яшькә җитмәсәм дә,
Алтмышны уздым инде.
Алай да мин бәхетсез дип,
Зарланыйммы? Ә нигә?
Рухымны бүләк иткәннәр,
Рәхмәт әти-әнигә!

**ЗӨЛӘЙХА**
(БӘЕТ)

Кичке сәгать тугыз булган,
Син дөньядан киткәндә.
Яннарыңда була алмадым.
Соңгы сүзең әйткәндә?

Әйтмәдең дә кайда, кайчан
Саулыгыңны алдырдың?
Ярый әле истәлеккә
Сүрәтеңне калдырдың.

Сүрәтең куен кесәмдә
Карыйм да куям шунда.
Булгансың икән син минем
Аем да, кояшым да.

Әй, әй, Зөләйхам!
Аклы күлмәк алдырдың.
Картлыгымда терәк өчен
Өч баһадир калдырдың.

Булгансың икән син минем
Индийский чәем дә.
Җанга рәхәт, тәнгә җылы
Сандугачлы җәем дә.

Әй, әй, Зөләйхам!
Аклы күлмәк калдырдың.
Үзеңне хәтерләтергә
Гүзәл бер кыз калдырдың.

Булгансың икән син минем
Җиләкләрем бакчамда.
Күз алдымнан һич китмисең
Күзне йомып баксам да.

Әй, әй, Зөләйхам!
Аклы күлмәк алдырдың
Син бит минем күңелемдә
Бары ак эз калдырдың.

Күңелләрем буп-буш калды,
Син генә биләгәнсең.
Минем бөтен тормышымны
Син генә бизәгәнсең.

Изгелекләрең күп булды
Мәңге оныта алмамын.
Син яртысын, мин яртысын
Ашый идек алманың.

Печән чабармын дисәм дә
Чаптым инде күрән дә.
Һуштан язам күл өстендә
Ялгыз аккош күргәндә.

Ялгыз аккош йөзә күлдә,
Артында кала күбек.
Картаймыш көнемдә калдым
Шул ялгыз аккош кебек.

Күңелемнән елыйм, ә күзләрдән
Чыкмый инде сыгылып яшем дә.
Ялгыз каен кебек калдым синнән
Илле тугыз яшемдә.

Ниләр генә үстермәдек,
Кайсылары уңмады.
Алай да бит безнең яшәү
Зарланырлык булмады.

Шомырт чәчәк аткач, сине
Күрәм күк терелтә.
Ул синең яшел күлмәктән
Торганны хәтерләтә.

Ташлап киттең, ялгыз иттең,
Юк бит синдәй ишләр дә.
Төшләремә кереп булса да,
Әйт, хәзер миңа нишләргә?

**Мансура.**

Сахраларда җыр җырласам,
Җил очырта, Мансура!
Сагындым шул, ышанмасаң,
Искән җилләрдән сора!

Болыннарда чәчәкләрне
Сиңа җыям, Мансура!
Юксынам шул, ышанмасаң,
Сары чәчәктән сора!

Су буенда суга карыйм,
Күрмәмме дип, Мансура!
Зарыгып көтәм, ышанмасаң,
Агым сулардан сора!

Кичкә керсәм, күккә карыйм,
Айдан эзлим, Мансура!
Өмет өзмим, ышанмасаң,

Зөһрә йолдыздан сора!

**Җитмәгән “ни” – син икән.**

Ашыйм дисәм, ашым бар,
Эшлим дисәм, эшем бар.
Әмма миңа нидер җитми,
Шул борчу күңелдән китми.

Ял итәргә бакчам бар,
Тотыйм дисәм, акчам бар.
Әмма миңа нидер җитми,
Шул борчу күңелдән китми.

Чиккән кульяулыгым бар,
Зарланмыйм, саулыгым бар.
Әмма миңа нидер җитми,
Шул борчу күңелдән китми.

Сокланырга талым бар,
Куанырга малым бар.
Әмма миңа нидер җитми,
Шул борчу күңелдән китми.

Борчылудан җир әйләндем -
Туган илем киң икән.
Тик соңыннан гына белдем,
Җитмәгән "ни" - син икән.

## ГАФИЯ БУЛАНОВА ФӘЙРУШИНА



Фәйрушина Гафия Әхмәдиша кызы 1937 елда Бондюг районы Бәзәкә авылында колхозчы гаиләсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлап, Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Аны бетергәннән соң, тырыш, бер эштән дә курыкмый торган кыз, институтның тәҗрибә станциясендә фәнни хезмәткәр булып эшли. Соңрак үзебезнең районда Бигәш авылында, 1966 елдан 2000 елга кадәр, баш агроном, берара авыл Советы рәисе булып эшли. Ул, 5 бала анасы буларак, “Ана даны” медале белән бүләкләнгән хатын-кыз.

Олыгайган көннәрдә Гафия ханым балачагын, яшьлеген, туган авылы Бәзәкәне сагына. Аның җаны йомылып яши алмый, хисле күңеле шигырьләргә күчә.

Үзенең 80 еллык юбилеена Гафия Фәйрушина үзе иҗат иткән шигырьләр бәйләменнән “Гомер юлым” (2017ел) дигән китабын бастырып чыгарды.

**Бәзәкәмә-500 ел!**

500 яшең тулды быел,
Туган авылым Бәзәкә.
Һәр эштә гел әйдәп бардың,
Бик тә лаек син хөрмәткә.

Иминлеге өчен илемнең
Канын койды улларың.
Кырларда иген үстерде
Кызларың, балаларың.

И халкым, ни генә күрмәде

Синең газиз башлар...
Табылды үткәнең турында
Язылган изге ташлар.

Юк-барга исең китмәде,
Җиңеп бардың барсын да.
Үз динеңне саклап калдың
Чукындырган чагында.

Авыл бүген нык үзгәргән,
Зурайган, матурайган.
Йортлар заманча салынган,
Искеләр яңартылган.

Талантлы шәхесләрең күп,
Санап чыгарлык түгел.
Барыгызга саулык теләп,
Рәхмәт әйтәбез бүген.

Тырыш хезмәтегез белән
Күтәрәсез авыл данын.
Танылганнар исемлеге
Артырга язсын тагын.

Барыбыз исән-сау булып,
Яшик алга омтылып.
Бергә яшәрләргә язсын,
Кан туганнардай булып.

**РӘХМӘТ СИҢА.**

Туган авылым Бәзәкә,
Сагынамын мин сине.
Мин бит синдә туып үстем,
Таныйсыңмы син мине?

Туган авылым Бәзәкә,
Сагындым урамнарың.
Узган балачагымны,
Яшьлегемнең елларын.

Авылымның урамнарын
Җырлап үтәсем килә.
Йөрәгемнең ярсуларын
Шулай басасым килә.

Гомер юлымда мин синең
Елгыр колының булдым.
Авылым, миңа син газиз,
Ярый мин синдә тудым.

Бала чагым, үсмер чагым,
Синдә үтте яшьлегем.
Торган җирем рәхәт булса да,
Сине сагынып яшимен.

## ХӘТИРӘЛӘР.

Әй, табигать, синең кочак
Ник шундый җылы икән?
Син аласың мине кочып,
Ә мин изерәп китәм.

Мин үстем синең кочакта
Аю баласы кебек.
Таптадым урман, аланың,
Йөрдем һәр җирең күреп.

Аунадым мин болыныңда
Печән исләрен иснәп.
Әрәмәндә җимеш җыйдым
Тутырып тырыс, чиләк.

Күл, елгаңда балык тоттым
"Мурда", ятьмәләр белән.
Пинәрәңдә йөздем көймәдә
Су ишеп ишкәк белән.

Утын ташыдык ягарга
"Уфалла" арбасы белән.
Тирләп-пешеп йоклый идек
Шуның җылысы белән.

Юа, кузгалак һәм кукы
Җыйдык капчыклар белән.
Шуларны ашап ачлыктан
Исән калганны беләм.

"Басу, болын бозасыз",- дип,
Истә атларда куган.
Әле дә чыбыркы эзләре
Аркамда әрни сыман.

## УКЫТУЧЫГА.

Укытучы - Олуг кеше,
Гыйлем-серләргә өйрәтә.
Аң-белем, тәрбия биреп,
Баланы кеше итә.

Бу хезмәткә ни әйтәсең-
Рәхмәт диеп әйтмичә.
Киләчәктә тормышың юк
Фәннәр нигезен белмичә.

Безгә нык белем биргәнсез
Үзегезне аямыйча.
Күңелемдә гел яшисез
Хәзер дә он(ы)тылмыйча.

Әле исән-сау булганнар
Сау-сәламәт торсыннар.
Инде арадан киткәннәр –
Оҗмахларда булсыннар.

**АВЫЛЫМ ЗЫЯРАТЫ.**

Каршы ала,
Озатып кала
Авылым зыяраты.
Кемнәр генә ятмый монда:
Әби, бабай, баласы.

Вакыт булса,
Эчкә керәм,
Йөрим язулар укып.
Исем, фамилия, ничә яшь
Язылган ташка чокып.

Кабер өстендә
Агачлар
Урман булып үскәннәр.
Бар да җәннәттә булсыннар,
Мәңгелеккә киткәннәр.

"Саумы,
Исән бул",-диеп,
Дәшәләр кебек миңа.
Минем дә әти-әнием
Яталар күптән монда.

Рәхмәт яусын
Бабайларга,
Гел дә карап торалар.
Чистарталар, кадаклыйлар,
Төзәткәләп куялар.

Һәркемнең дә мәңгелеккә -
Шушы йортка
Кайтасы бар.
Барыбызны кочагыңа,
Зыяратым, каршы ал.

**ҺӘЙКӘЛ КУЯРЛЫК**.

Агач, чәчәкләр турында
Бик күп җырлар җырланган.
Тик үләннәр җырларда юк,
Алар чәчәк атмый җыелган.

Юа белән кузгалакны
Җыйдык капчыклар белән.
"Печәнлекне бозасыз",-дип,
Кудылар атлар белән.

Басулардан да кудылар,

"Җирне бозасыз",-диеп.
Өшегән бәрәңге җыйдык
Ачтан үлмәек диеп.

Әле тагын калган икән
Алабута, кычыткан.
Халкым шуларны ашап,
Исән калды ачлыктан.

Тик ул үләннәрне хәзер
Юк искә дә алучы.
Һәйкәл куярлык аларга -
Алар безне коткаручы.

**ЯТИМ ҮСМӘСЕН БАЛАЛАР.**

Авылым, сине ташлап киттем,
Тик китмәдем синнән туйганга.
Үкси-үкси елап киттем,
Үги әни куганга.

Үги ананың яхшысы да
Козгын кебек була диләр.
Чокып тора ятим баланы,
Күрсәтми ул аңа ниләр.

Ничек кенә тырышсаң да,
Яратмый ул синең эшне.
Газиз әнкәңнән дә кадерле
Җирдә бармы башка кеше.

Кагу-сугуларга түзә бала,
Ничек чыдый аның йөрәге?
Әти-әнисеннән җылы наз көтеп,
Үтә аның һәрбер көне.

Бер балага да язмасын
Үги ана “тәрбиясен” татырга.
Кимсенеп һәм җәберләнеп,
Ятимлектә газапланырга.

Ходай гомерләрен биреп,
Исән булсын ата-аналар.
Гаиләләр тату, имин булсын,
Ятим үсмәсен балалар.



**МАНСУР МӨХӘМӘТДИН УЛЫ ХУҖИӘХМӘТОВ**

Хуҗиәхмәтов Мансур 1947 елны Бондюг районы Бәзәкә авылында туа. Урта мәктәптә бик тырышып укый, аеруча рус теле фәнен ярата. Үги әтисенең энесе үзен Кыргызстанга алып китә. 3-5 сыйныфларны шунда укый, әмма бик сагынып, кабат әйләнеп кайта, укуын туган авылында дәвам итә. Өлкән сыйныфларда бик тырыш, актив була: кичәләрдә матур итеп шигырьләр укый, концерт программаларын алып бара. Алга таба ДОСАФта укып, шофер була. Армиядән соң колхозда мастерской мөдире булып эшли.

**Туган авылым**

.

Минем авылым бигрәк матур,
Исеме аның Бәзәкә.
Урамнары төз һәм матур,
Кешеләре бигрәк тә.

Чишмәләре челтерәп ага,
Инеш буе тал-тирәк.
Сандугачлар чут-чут сайрый,
Мондый авыл бик сирәк.

Баллы чишмә, Олы чишмә,
Изге чишмәсе дә бар.
Тәннәреңә сихәт керер,
Су эчеп, ял итеп ал.

Таң атканда бигрәк матур
Җиләкле аланнары.
Көзгә тагын кызарырлар
Миләше, баланнары.

Матур аның урманнары,
Басулары, кырлары.
Шуңа күрә теләсәм дә,
Ташлап китеп булмады.

Тургайлары өздереп сайрый
Аланнарда, тугайда.
Ташламагыз авылыбызны,
Китмәгез сез беркайда.

Авылыбызны ишәйтеп,
Килсен уңган киленнәр.
Һич тә китәргә дип түгел,
Гомерлеккә килсеннәр.

Шулай булса, авылым яшәр,
Туып торыр сабыйлар.
Алар инде ташлап китмәс,
Туган җирдә калырлар.

Яшә син, туган авылым,
Яшә гомер-гомергә.
Яшьнәп яшик дуслар булып,
Туган булып гел бергә.

**БЕРГӘ ҮСТЕК ДҮРТ МАЛАЙ**

Сугыштан соң туган балалар без.
Без дүрт малай үстек ул чакта.
Сугышмадык, тату булып үстек,
Бәрәңгеләр күмеп учакка.

Сугыштан соң туган балалар без:
Ике Мансур, Флүр һәм Сәет.

Урамнарда "Әссәләти" әйттек
Җиткән көнне Корбан гает.

Кармак белән ташбашлар да тоттык,
Балтырганын җыйдык, юа, кукысын.
Белеп үстек, шуңа сөендек без,
Ун ел әле бергә укысын.

Мәктәптә дә без әйбәт укыдык,
Аерылмадык, булдык гел бергә.
Шулай яшик дидек,дуслар булып,
Тату булып яшик гомергә.

Үсеп җиттек, сизмичә дә калдык,
Егет булып инде җиткәнбез.
Шулай килеп чыкты, аерылыштык,
Еракларга чыгып киткәнбез.

Солдат боткасын да ашап кайттык
Шинель салып ныгыган иңнәргә.
Хыялланып яши башладык без,
Ни буласын белми иртәгә.

Кинәт беркөн кара болыт булып,
Начар хәбәр килде каладан.
Кырык сигезен дә тутырмый,
Сәет дускай китте арадан.

Рәнҗемә син безгә, Сәет дустым,
Хәл белергә киләм ел саен.
Әйтә сыман,"онытмагыз" диеп,
Кабереӊ янында үскән яшь каен.

Әҗәлләргә сабырлыклар биреп,
Безне Ходай әле яшәтсен.
Күңелләргә иман нуры сибеп,
Якты дөньяда, Раббым, яшәт син.

**ХӘТЕР САНДЫГЫ**

Яшьлек үткәч ничек моңаймыйсың,
Йөрәк сызлый, яна ул көеп.
Күзге яңгыр сыман берөзлексез
Борчып тора теңкәгә тиеп.

Яши торгач шулай бервакытны,
Хәтер сандыгымны ачып ташладым.
Барлап чыгып һәрбер үткән елны,
Истәлекләр белән яши башладым.

Уйланам да барып утырамын:
Кемнәр авылымны ташлаган,
Кемнәр инде бакыйлыкка күчкән,
Кемнәр яңа яши башлаган.

Авылда бит бар да күз алдында,
Бернәрсәне булмый яшереп.
Яшь йөрәкләр гел кавышып торса,
Авыл китә кебек яшәреп.

Эх, офтанмыйк, яшик әле, яшик,
Яңа туган көнгә сөенеп.
Гомер итик туганнардай кебек,
Йөрмик әле гел дә көенеп.

Хәтер сандыкларыбызда безнең
Яманлыклар тулып ятмасын.
Матур яшәдегез, әйдә, яшәгез, дип,
Ходай безне үзе сакласын.

**ҮГИ БАЛАЧАК**

Нигә шулай ачы була икән
Үгилектә үткән балачак?
Онытылмас ул, мәңге онытылмас,
Үлгәнче ул истә калачак.

Үгилектә үстем үзем дә мин,
Ачлы-туклы үтте көннәрем.
Шуңа күрә авылымны ташлап,
Чыгып киттем, чөнки түзмәдем.

Чит җирләрдә рәхәт яшәсәм дә,
Сагындырды туган якларым.
Үзәкләрем өзелердәй булып,
Сагынып кайттым, анда калмадым.

Менә шул вакытта антлар иттем
Ташламаска туган ягымны.
Сандугачлы, челтер чишмәле
Туып үскән туган авылымны.

**ГАЗИЗ ӘНКӘМӘ**

Китмә әле, әнкәй, күз алдымнан,
Исән кебек тор гел янымда.
Янып тор син әле, гел янып тор,
Маяк булып гомер юлымда.

Кил яныма, улым, дип, гүя дәшәсең,
Гафу ит, әнкәй, килмим әле.
Иртә киткән абыем, энем өчен
Минем яшисем бар бит әле.

Үпкәләмә, әнкәй, һич онытмыйм,
Төшләремә кереп торасың.
Өлешемә тигәнен яшимче,
Белмим алда ниләр күрәсен.

Бүген, әнкәй, тагын төшкә кердең,

Белмим инде хәзер нишләргә.
Әллә инде миңа рәнҗеп киттең,
Биреләм газаплы хисләргә.

Сугыштан соң авыр чорлар иде,
Әмма бирешмәдең, сынмадың.
- Я, Ходаем, ярдәм ит син миңа,
Исән булсын,-дидең, - улларым.

Соңгы телем икмәгеңне биреп,
Сакладың син безне, үстердең.
Бик газаплы булды тормыш юлың,
Кайгы-хәсрәтләрне күп күрдең.

Язмыш сине тагын сынамакчы булды,
Бик зур кайгы килде башыңа.
Ике улыңны син югалттың
Һәм тезләндең Ходай каршына.

Ничекләр күтәрдең бу хәсрәтне,
Телгәләнгәндер, әнкәй, йөрәгең.
Авылдашлар барсы күрде, белде,
Бу кайгыга ничек түзгәнең.

Рәнҗемә син, әнкәй, тыныч йокла,
Гомер теләп соңгы улыңа.
Гел дә килеп торамын яныңа,
Дога кылам синең рухыңа.

**КҮЗ АЛДЫМДА ӘНКӘЙ ЧАГЫЛА.**

Куй әле син, әнкәй, самоварыңны,
Баллы чишмә суын тутырып.
Эчик әле чәйне каты итеп,
Кара-каршы бергә утырып.

Чәйнегеңә сал син такта чәйне,
Яшел кәгазьгә төргәнен.
Олы шакмак шикәреңне дә ват,
Тәмләп эчик Ходай биргәнен.

Күп чагында шулай хыялланам,
Күз алдымда әнием чагылса.
Яраланган аккош кебек булам,
Йөрәгемә сагыш кагылса.

Көтмәгәндә, бер дә картаймыйча,
Китеп бардың, әнкәй, арадан.
Көчсез бит без Ходай каршысында,
Белмибез, кемгә күпме саналган.

Рәнҗемә син, әнкәй, тыныч йокла,
Мин еш барам синең яныңа.
Игелекле, мәрхәмәтле булу
Синең җаннан күчкән җаныма.

Инде мин дә җиттем синең яшькә,

Сизелми дә гомер агыла.
Син дә әзерлән, олыгайдың дип,
Йөрәгемә картлык кагыла.

Мин тормышка бик нык гашыйк кеше,
Язгы җилдәй назлы йөрәгем.
Хәер-дога белән китсәм иде дип,
Гомерем буе шуны теләдем.

**АВЫЛ ГАРМУНЫ**

Эх, җырларга иде бер туйганчы,
Гармун тавышына кушылып.
Һәм... яшәргә иде, гомер буе
Җырлар, моңнар белән бер булып.

Йөрәкләргә үтеп керә икән
Шул гармунның сихри моңнары.
Хәтта сандугач та тып-тын калып,
Сайравыннан туктап тыңлады.

Уйнагыз сез рәхәтләнеп гармун,
Авыллардан яшьләр китмәсен.
Сөешсеннәр, кавышсыннар алар,
Тик авыллар гына бетмәсен.



**ӘКЪЛИМӘ МУЛЛАХМӘТ КЫЗЫ СӘХӘБИЕВА**

Сәхәбиева Әкълимә Татар Тәкәше кызы, Бәзәкә авылы килене. 1944 елда күп балалы колхозчы гаиләсендә туа. Башлангыч сыйныфны туган авылында, 8 еллык белемне 8 чакрым ара йөреп, Сәйтәк авылында ала. Гаилә тормышы авыр булу сәбәпле, югары белем алырга мөмкинчелеге булмый. 1962-1964 елларда авылда клуб мөдире булып эшли. 1965 елда Бөгелмәдә сатучылык һөнәрен үзләштерә һәм сатучы булып эшли. Гомеренең күп өлешен Әкълимә Муллахмәт кызы Нижневартовск шәһәрендә яши. Шигырьләрен дә шунда яза башлый. Себернең кырыс, әмма гүзәл табигате күзләрне назласа да, туган үскән авылы Тәкәшнең матурлыгы, шифалы чишмәләре бер минутка да истән чыкмыйлар. Аның күңелендә үзеннән үзе шигырьләр туа.

Бүгенге көндә Менделеевск каласында яши, шигырьләр язуын дәвам итә, алар районыбыз газетасында басылып киләләр..

**ЛАЕКЛЫ ЯЛДА**

50 яшемә багышладым.

Узып китте гомерем – ярты гасыр ,
Хыялларым ашты тормышка.
Алдагысын бары Аллаһ белә,
Берни әйтеп булмый язмышка.

Яшьлегемнең кадрен белмәгәнмен,
Очып узган еллар кош булып.
Бусагамнан атлап керде картлык,

Көтмәгәндә миңа кул сузып.

Чәчкә чаклар бик тиз узып китте,
Тормыш юлларында бәйләнеп.
Гөлләр булып чәчкә атар идем,
Яшьлекләрем кайтса әйләнеп.

Көннәр, айлар, еллар – гомер уза.
Изге теләк телим һәр көнем.
Ак яулыгым, ак күлмәгем белән,
Шатландырсын картлык көннәрем!

**КЫР КАЗЛАРЫ**

Кыр казлары очып китте бүген,
Түгәрәк күл, сине калдырып.
Һава юлларында киртәләр юк,
Канатларын җилгә талдырып.

Яз каршылап, көз озатып ел да,
Ни әйтәсең мондый язмышка.
Оя корып балалар очырган
Камышларын салып сагышка.

Үз язмышын һәркем үзе белә,
Сорау биреп булмый кошларга.
Җылы якка очып җитү өчен
Нык канатлар кирәк аларга.

Зәңгәр булганга син, түгәрәк күл,
Зәңгәрләнәме икән һавалар?
Артларыннан калмый очар идем,
Юк шул миндә каурый канатлар.

Бик озаклап басып карап калдым,
Кыр казлары очкан якларга.
Исән-сау йөреп, кабат кайтыгыз
Сагынып туган якларга.

**ГОМЕР ӨСТӘЛӘ БАРСЫН!**

Кояш нуры балкып торсын,
Гомер өстәп һәр көн дә!
"Бирче , Ходай, сабырлыклар",-дип,
Сорыйм калган гомергә.

Шатлыклы картлык көннәргә,
Гомер өстәлә барсын!
Туймадык әле дөньядан,
Озак яшәргә язсын!

Дингә карышып яшәүнең,
Булмагач файдалары.
Кала саен калкып чыкты,
Мәчет манаралары.

Зур белемле яшь аналар,

Укытканнар мәктәптә.
Хәзер шул хатыннар йөри,
Намаз укып мәчеттә.

Ислам дине догаларын,
Яттан белергә кирәк!
Изге эшләрнең гыйлемен
Дәвам итәргә кирәк!

**КОРБАН БӘЙРӘМЕ**
Корбан ашы булып узды
Беренче сентябрьдә.
Ике сарык бугазланды
Олы Бәйрәм көнендә.

Матур, аяз, кояшлы көн –
Теләк кабул булганга.
“П” хәрефенә охшатып
Өстәлләр куелганга.

Корбан сарык чалынды,
Зур казан да табылды.
Балта белән туракланып
Ит казанга салынды.

Габделнур утын ыргыта,
Рәвил итне болгата.
Өч хатын бәрәңге турый,
Алар күмәк эш ярата.

Рәхим итегез, кунаклар,
Корбан бәйрәм ашына!
Мулла да килеп утырды,
Чалма киеп башына.

Түр башында утырганнар –
Бар да туган-тумача.
Ак яулыктан, түбәтәйдән
Кода белән кодача.

Шундый Корбан ашлары
Гел булып торса иде.
Шәригать кушуы буенча,
Бердәм яшәсәк иде!

**ЯРКАНАТ.**
Кош та түгел очар өчен,
Канаты бар - каурыйсыз.
Бакага да охшамаган,
Тычкан дисәм - койрыксыз.

Кул-аяклар – канат аның,
Яшәү өчен уңайсыз.
Әллә төн күбәләгеме?
Төнлә оча холыксыз.

Кояш баеганын һәр көн көтә

Таш койма арасында.
Бәхетенә тигән өлеш,
Зарланмый язмышына.

Җәтмә тырнак канатлары,
Янып тора күзләре.
Чебен-черкиләрне аулап,
Җитми кала төннәре.

Таң алдыннан кереп поса,
Талмаса да канаты.
Төнлә генә очар өчен
Яралган яркcanаты.

## ИЗГЕ ЧИШМӘ

Фан чишмәсенең исеме
Хәтердә калган минем.
Балачаката шул урында
Бәбкәләр саклый идем.

Әүлияләр каберендә
Өч тал үсә, берсе куш.
Билге өчен куелган таш
Югалган, урыны буш.

Агымсуларың саф, чиста
Ком-ташлардан саркыганнан.
Көмеш сулар челтерәп ага
Вак ташлар арасыннан.

Гомер буе аккан суның
Иганәчесе табылды.
Татлы сулы Изге чишмә
Үзгәртелеп корылды.

Бәзәкәнең уңган улы –
Рәхмәт Минегалигә!
Халык өчен мирас булып,
Даны калсын мәңгегә.

Изге чишмәгә килегез
Татлы суын эчәргә.
Файдасы, шифасы тисен,
Көчен бирсен яшәргә!

## ФАН ЧИШМӘСЕ

Әниемнең аклы күлмәкләрен
Барып чайкый идем улакта.
Челтерәп аккан чишмә суларында,
Ком, ташларга басып ул чакта.

Фан чишмәсе диеп исемләнгән
Изге чишмә элек-электән.
Заманында әби-бабайлар да

Татлы суын эчеп көн иткән.

Җир астыннан агып чыгасың да,
Ерак-еракларга китәсең.
Кайсы диңгез, күлнең тармагы син,
Халкым өчен хезмәт итәсең?

Гомер торган кабер ташын күрәм,
Анда изге җаннар күмелгән.
Сихәтләнер өчен суларыңны эчәм,
Җирдә ятып йоклап төш күрәм.

Исләремдә, хәтеремдә калган
Яннарыңа утырып ял иткән.
Чиләкләрне тутырып алып,
Күтәреп кайтып киткән.

Изге урын. Ерак дәверләргә,
Гасырларга тиңдәш Фан чишмәм.
Учларыма алып суым эчәм,
Гомер теләп, сиңа баш иям.

**АЛТЫН КӨЗ**

Йолдызларга карап сокланам,
Көнләшәмен тулган айга да.
Я, Ходаем, бирче сабырлыклар
Күрешмичә торган айларда.

Күк йөзендә йолдызлар күп,
Бар арада балкып янганы.
Җирдә дә бар якын дусларымның
Йөрәгемдә урын алганы.

Ай төн өчен булса, кояш көн өчен,
Йолдызлары яна кем өчен?
Яшен яшьнәп, күк күкрәп уза,
Җил-давыллар куба ни өчен?

Кара болыт каплый һаваны,
Коеп ява башлый яңгыры.
Салават күперен кем төзегән?
Табигатьнең юк бит куллары.

Дүрт вакытны үз эчеңә алган
Табигатем, сине яратам.
Кышың, язың, җәйләрең бик матур,
Ә мин үзем көзне яратам.

Күңелемә кереп калдың минем
Көзге яңгырың белән.
Кызгылт-сары төскә кергән
Моңсу урманың белән.

Пушкин да бит сөйгән көз айларын,
Есенин да көзне яраткан.
Алтын көзләр алтын төсе белән

Күпләрне бит үзенә караткан.

Бушап калды кыр, басулар,
Шәрә калдың, урманым.
Озакламый кышың килеп җәяр
Кардан сырып юрганын.

Табигатьнең үз законы –
Ничек тели, шулай эшләргә.
Ул сорамый бездән ярдәм кулын,
Кайчан, нинди төстә яшәргә.

Җәен күмсә яшеллеккә,
Кышны буый ап-ак карларга.
Язы була аклы-каралы,
Сары төсен саклый көзләргә.

Алтын да бит сары төстә,
Сабырлыклар була саф алтын.
Бала чактан сөйдем сары төсне,
Әллә шуңамы көзне яраттым.



**ФӘҺИМӘ МИННӘХМӘТ КЫЗЫ ГАЛИМОВА**

1957 елда Бондюг районы Бәзәкә авылында колхозчы гаиләсендә туа. Мәктәптә бик тырышып укый һәм аны4-5 билгеләренә генә тәмамлый. Гаилә хәле буенча алга таба югары белем алырга мөмкинлеге булмый һәм, парта арасыннан чыгу белән, эшкә керешә, мәктәптә сәркатиб вазифасын башкара. Аннары 26 ел дәвамында саклык банкында контролер-кассир, 3 ел авыл кибетендә сатучы булып эшли.

Фәһимә ханым китап укырга, бәйләргә, чигәргә ярата, башкаларны да өйрәтә. Авылда оештырылган чараларда актив катнаша. Үзе өчен генә күңеле түрендәге уй-хисләрне кәгазь битенә төшерә. Бүгенге көндә туган авылында, алга чынга ашмас максатлар куймыйча, тормыш иптәше белән уллары һәм оныкларына сөенеп, тыйнак кына гомер кичерә.

**ТУГАН КӨН.**

Тиздән туган көнең җитә, дисең,
Нәрсә бүләк итим, ни кирәк?
Минем өчен иң зур бүләк ул –
Чын күңелдән котлап әйткән теләк.

Өстәл тирәли дуслар җыелган,
Табын өсләрендә сый-нигъмәт.
Йөрәгемә бик тә рәхәт була
Сезнең миңа әйткән теләк.

Менә тагын шаулап язлар килә,
Ә мин керәм гомер көземә.
Калган гомеремә сәламәтлек
Сорыйм бер Ходайдан үземә.

Гөл-чәчкәләр сөям, сез аларны
Сулар сипми корытмагыз.
Арагыздан иртәрәк китсәм,
Зинһар, мине онытмагыз.

**ҖИРДӘ ЯШӘҮ БУЛМАСЫН ЗАЯГА**

Әллә ни кирәкми миңа,
Ходай биргәнгә канәгать.
Гомер буе җыйган малны
Таратырга җитә бер сәгать.

Янәшәмдә ике балам
Игелек кылып торса.
- Син миңа кирәк,-дип, ирем
Елмаеп кулын сузса.

Мине үз, якын иткәннәр
Табын түремә узса,
Бәхетлемен, миңа шул җитә,
Мин шуңа да бик риза.

Яз җитүгә сокланамын
Кар гөле - умырзаяга.
Телим теләк: җирдә яшәвем
Булмасын дип заяга.

**ХУШЛАШУ**
(Колхоз рәисе Ибраһим Галимов вафатына)

Әллә инде табигать тә бүген
Синең белән мәңгегә хушлаша.
Тәрәзәдән үрелеп кояш карый,
Әйтерсең лә күз яше ага.

Әле коеп яңгыр ява, әле кар.
Раббым,нигә соң тормыш сөйгәннәргә,
Әле яшьнәп яшим дигәннәргә,
Якты дөньяларда урының тар?

Авыл тынып, моңсуланып калды,
Басу-кырларда да бетте ямь.
Йөрәкләрне безнең телеп киттең,
Яшәү өчен бетте кебек гамь.

Дөнья куабыз, мал җыябыз,
Беләбез бит бер көн каласын.
Ходаем, ник соң яхшыларны
Үзеңә бик иртә аласың?

Җылы яктан киек кошлар кайта,
Туган якларын сагынып,өзелеп.
Ә син кайттың туган туфрагыңа
Ап-ак кафеннәргә төренеп.

**ЯКТЫ ЭЗЕҢ КАЛСЫН.**

Иссен җилләр, үтсен көннәр,
Балкып ян, бирешмә, йөрәк.

Мин бит әле япь-яшь диеп,
Яшьнәп яшәргә кирәк!

Дөньялары авыр дибез,
Кемсоң аны үлчәп караган?
Ямь-гамь табып яшик әле
Шушы авыр, әмма якты дөньядан.

Дөньяда яшәүдән ни мәгънә:
Нихәл, диеп, күршең кермәсә.
Үзеңнән соң сине сагынып,
Сөйләргә дус-ишең булмаса,
Җирдә якты эзең калмаса.

**ГӨЛСӘРИЯ РӘФӘГЕТДИН КЫЗЫ ФӘТХУЛЛИНА**



1969 елда Бәзәкә авылында колхозчы гаиләсендә туа. Урта мәктәпне 1986 елда тәмамлап, Әлмәттә пешекче һөнәрен үзләштерә һәм НГДУ "Прикамнефть" тә пешекче булып эшли. Туган авылын, аның табигатен, җир суын, мал-туар, терлекләр яратуы яшь кызны колхоз фермасына китерә. Ул 30 елга якын сыер сава, бозаулар карый. Эшен яратып, җиренә җиткереп эшли, һәрчак мактаулы урыннар ала. Хезмәте авыр булуга карамастан, аның нечкә күңелен кайчак шигъри хисләр били һәм бу хисләрдән, кечерәк кенә булса да, шигырьләр туа.

**ТУГАН ЯК**

И ямьле дә минем туган ягым,
Тезелеп киткән урман-кырлары.
Күлләренә аккош төшә,
Сагындыра шул чагы.

И ямьле дә минем туган ягым,
Игеннәре үсә дулкынлап.
Шушы рәхәт тормышыма,
Башымны иям зурлап.

**ЯЗЛАР**

Менә тагын язлар җитте,
Кояш балкый авылым күгендә.
Шушы язда мәхәббәтем кабат
Чәчәк атты йөрәк түремдә.

Син диеп тибә йөрәгем,
Һәр сулышым сиңа тартыла.
Сөйгәнем син, кадерлем син,
Беркайчан да мине ташлама.

**СОҢГЫ ӨМЕТ**

Соңгы өметем дә
Өзелә инде, күрәмсең.
Минем өчен насыйп булган
Яр түгел лә икәнсең.

Йөрәк тибә тибәр-типмәс,

Күзләр моңлы, яшьләр кипмәс.
Мине ташлап китүеңне
Йөрәккәем гафу итмәс.

**ХУШЛАШУ**

Кояшлы бер аяз көнне
Яшен суккандай булды.
Язмыш  кырыс, нигә шулай
Йөрәгемә ут салды.

Мәхәббәтең, диде, сине
Алыштырды башкага.
Йөрәгемнән, бәгърем, сине
Ничек алып ташларга.

Ә соң сине йөрәгемнән
Алып ташлап булырмы?
Әллә инде үткәннәрне
Сагынырга калырмы.

Мәхәббәтнең кайнар утын
Йөрәгемдә кабыздың.
Хәзер шуның утларында
Дөрләп янам ялгызым.

Соңга калып ник килдең син,
Мәхәббәт, йөрәгемә?
Үз тиңнәрем була алмагач,
Ник карадың күземә.

Соңгы тапкыр мин моңланып,
Синең белән хушлашам.
Шушы авыр минутларда,
Мин бит ялгызым калам.



**ШӘРГЫЯ ИБӘТУЛЛА КЫЗЫ ИБӘТУЛЛИНА**

1928 елда Бондюг районы Бәзәкә авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Сугыш башланганда, 7 класс тәмамлап, колхозда эшли. 1950-1953нче елларда Алабуга культура агарту училищесында укый. Матур җырлый, сәнгатьле итеп шигырьләр сөйләргә ярата. 1953 елда Бәзәкә клубында мөдир булып эшли, мәдәни чараларны бик еш һәм оста оештыра. Берара балалар бакчасында тәрбияче була. 1963 елдан 1988нче елга кадәр, нәкъ 25 ел, авыл советында баш бухгалтер эшен башкара. Нечкә күңелле, моң-җыр сөюче, инде 9нчы дистәне ваклаган Шәргыя ханым, шигъриятькә гашыйк, үзе дә каләм тибрәткәли. Арабыздан бик иртә киткән яшьләр өчен аеруча нык борчыла, үртәлә һәм, кулына каләм алып, бәет-мөнәҗәтләр яза башлый.

**ХАҖИНУР БӘЕТЕ.**

Гыйнвар ае. Карлар ява.
Кар ява, яңгыр ява.

Авылдашлар Хаҗинурны
Зыяратка озата бара.

Бар иде авылыбызның
Нурлы бер Хаҗинуры.
Йөзендә һәрчак елмаю,
Гүя җәннәт хозуры.

Шәһәрдә яшәсә дә ул,
Авылын онытмады.
Ярый әле нәселендә
Рифнуры бар, оныклары.

Җитмеш яшькә дә җитмичә
Китте безнең арадан.
Шулай тиз юкка чыгудан
Барыбыз аптыраган.

Үзенә юл ачып куйган,
Капка төбен күрәгән.
Бәлки төшендә күргәндер,
Әмма үләм димәгән.

Фәттах бабай җимешләре:
Сигез данә иделәр.
Күз ачып йомганчы менә
Бер башка кимеделәр.

Күршеләре, туганнары
Озатырга җыелды.
Сирәк күрә авыл халкы
Мондый олы "җыенны".

Дөньялары бозык, тик шулай да
Иманлы җан таба кыйбласын.
Йөрәк дулкынлана, и, Ходаем,
Изгеләргә җәннәт,исәннәргә
гомер юлласын.

**ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК**

Яшь тә дүрт айлык баласын
Гүзәл ана ташлап китте.
Ходай шулай яраткандыр,
Бер нишләп тә булмый инде.

Пар канатлы кошлар кебек
Очып йөрдек авылларда.
Язмышларны белмибез шул
Килеп чыга давыллар да.

Еллар үтте, акты сулар,
Гөрләп яшәү артта калды.
Килде бер көн, сулыш бетте,
Ходаем җанымны алды.

Айдар улым, син сеңлеңне

Ярата күр минем кебек.
Әбиеңә зур терәк бул,
Әти Мансур, син дә ишет.

Газиз анам, атам, Зиннур,
Бу балалар сезгә калды.
Октябрьнең кара бер көне
Сезне кайгыларга салды.

Исән калган җан дусларым,
Минем арттан ашыкмагыз.
Рәнҗетмәгез аналарны,
Яратыгыз балаларны.



## ГӨЛШАТ ФӘРӘХЕТДИН КЫЗЫ НӘҖМЕТДИНОВА

1955 елда Менделеев районы Бәзәкә авылында туа. Балалар бакчасына йөри, туган авылы мәктәбендә белем ала. Үтә тырыш, сәләтле укучы буларак, мәктәпне алтын медальгә тәмамлый. Алга таба, Казан Дәүләт Университетының юридик факультетында укып, юрист һөнәрен үзләштерә. 40 елга якын Чаллы каласында прокурор булып эшли. Эше үтә җаваплы, катлаулы булуына карамастан, Гөлшат йомшак күңеле, нечкә хисле кеше буларак, әдәбият, сәнгатькә тартыла, җырлар, шигырьләр ярата. Үзе дә шигырь язу белән мавыга. Тик шигырьләре башкалар өчен дә мәгълүм булу турында уйламый ул. Шигырьләрен сорагач:“Язганнарым ияләренә барып ирешсә, миңа шул җиткән”, - дип, җаваплый. Аның бер шигырен сезгә тәкъдим итәбез.

**ОЛУГ ТАБИБКА**
***(Табиб-хирург Рифкать Таҗиевка багышлана)***

Яшәү- мизгел. Ә бит шул мизгелне
Узар өчен кирәк сабырлык.
Сезнең тормыш – күпләр өчен үрнәк,
Уйлап баксаң – хәйран калырлык.

Сез ярдәм кулы сузасыз
Авыру- сырхауларга.
Өмет уты кабызасыз
Өметен җуйганнарга.

Иң яман чирдән дә, гүя,
Терелтә күзләрегез.
Һәмма дарудан сихәтле
Ягымлы сүзләрегез.

Шәфкатьледер йөрәгегез,
Нык түземлек сезгә хас.
Гел рәхмәт явып торса да,
Булыр сыман һаман аз...

Ап-ак халат төсле ак күңелегез
Ничек тапламыча йөрдегез...
Рәхмәт Сезгә, алтын куллы кеше,
Күпме жанга сихәт бирдегез!

Бик тә килешә ак халат

Ачык, якты йөзегезгә.
Кешеләргә кылган изгелек –
Меңе белән кайтсын үзегезгә.



**Гөлсәрия Мулламөхәммәт кызы**
**Галиева (Әхмәтҗанова)**

1957 елда Бәзәкә авылында эшче-нефтьчеләр гаиләсендә туа. 10 ел Бәзәкә мәктәбендә белем ала. 1975 елда авылның балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. 1976 елда НГДУ”Прикамнефть”нең беренче нефть һәм газ чыгару цехына диспетчер булып эшкә урнаша. 2002 елда НГДУның ТХУ-1 цехына лаборант булып күчә һәм пенсиягә киткәнче шул вазифасын башкара. Лаеклы ялга чыккач, күңелендә шигырь язу теләге уяна.

## Пинәрә күл

Табигатьнең бер матур җирендә,
Болын уртасында иде Пинәрә.
Яр буенда камыш, таллар үсеп
Утыралар кебек бүген дә.

Пинәрәнең зур болыннарында,
Җир җиләкләренең исләре.
Зифа камыш төпләрендә үскән
Юа суганнары тәмнәре.

Хәтерләрдә калды Пинәрә күл,
Онытылмаслык булып гомергә.
Су астында калса да йөргән юллар,
Күңелләрдә мәңге сакланырлар.

## Совет чоры баласы

Совет чоры баласы мин,
Бик сабыр һәм йомшак күңелле.
Күпме тырышсам да усал булып
Була алмадым каты бәгыръле.

Яшьли тәрбия алдым мин,
Әти-әни кагып йөртмәде.
Үсә төшкәч, Ленин васыятьләре
Маяк булып алга өндәде.

Киртәләр дә булды юлларымда,
Югалмадым, алга атладым.
Булмасам да бик зур түрәләр,
Һәрчак алда булдым, мактадым.

Рәхәтләрен тоеп яшим хәзер
Шул узылган тормыш юлымның.
Ходай ташламаса, ярдәм итсә,
Күпме калган, шуны узармын.

## Спасс ярминкәләре

Ел да сагынып көтәбез,
Август ае җиткәнне.
Алабугага күчеп килә
Спасс ярминкәләре.

Күреп бетерерлек түгел,
Андагы галәмәтне.
Бөтен Рәсәй җыелган бит,
И-и-и Ходайның рәхмәте!

Шашлык кыза, чәй кайный
Почмак саен мәйданда.
Алга таба атласаң-
Үзбәк пылавы анда.

Уңга карасаң - казылык,
Сулга карасаң- көлчә.
Осталар җыелган монда,
Үзенчә кунак итә.

Һәвәскәрләр һәм артистлар
Сәхнәдә биеп тора.
Җаны булган кешегә,
Кушылмый торып кара.

Шишкин буаларында
Күңел ачып кайтасың.
Ярминкә кутәнәчләреннән
Чәйләп авыз итәсең.

Имин булсын елларыбыз,
Ел да килсен кунаклар.
Без көтәрбез сезне сагынып,
Якын дуслар, туганнар.

## Төпчегемә багышлау

Матур язгы көн туды.
Төпчек кызым никахы.
Ап-ак карлар төшеп тора-
Шулдыр Ходай фатихасы.

Кар бөртекләре охшаган
Күктән яуган чәчкәгә.
Бәхетләрең булсын, кызым,
Рәхәт яшә мәңгегә.

Шатлыклар һәм сөенечләр
Гел дә тулып торсыннар.
Сәламәтлек, бәхет, тигезлек –
Озын-озак булсыннар.

Гөл-чәчкәләргә күмелсен
Узасы ак юлларың.
Бергә янәшәңдә булсын
Һәрвакыт сөйгән ярың

## Әни, мин кайттым

- Әни, тагын синең янга кайттым,
- Ярар, кызым, бик әйбәт, балам.
Шушы җылы сүзне ишетер өчен
Әни,синең янга кайтып барам.

Үзем ашыгам, янам, көям,
Кайт тизрәк, әниең начар диләр.
Йөрәккәем оча, дөп-дөп тибә,
Нидер булыр кебек, күңел сизә.

Җитешмәдем, юлым озын иде бик,
Күрә алмадың газиз кызыңны син.
Авыр сулап бер алдың да тындың,
Бездән мәңгелеккә китеп бардың.

Бүген менә тагын кайттым сиңа,
Туган бусагамнан атлап керәм.
Кабер тынлыклары ич биредә,
Син булмагач, әни, шыксыз өй дә.

Бар да үз урынында, бер тәртиптә,
Шул ук бүлмә, шул ук түшәк.
Тик түшәк буш, ялгыз, салкын үзе,
Теле булса әйтер иде назлы сүзне.

Башта төрле уйлар, искә төшә
Балачаклар, узган матур еллар.
Ерак калды, кире кайтмаслар,
Матур мизгел булып сакланырлар.

Шушы уйларыма уралып мин
Коръән алам кулга, дога кылам.
Әти-әни рухы шат булсынга,
Нигез хуҗалары булган һәркемгә.

Догаларым ирешәдер сезгә,
Төшкә кермисез бит берегез дә.
Начар төшләр күрмәсен дип балаң
Кабердә дә түзәсең, әни, мин сокланам.

Тормыш бирдең, назлап үстердең мине,
Кеше иттең, югалтмадың, ташламадың.
Урының булыр һәрчак йөрәгем түрендә,
Тыныч йокла, әнием, кабереңдә.

## Хыял

Утырдым да, хыялларга чумдым,
Үткән яшьлегемне сагынып.
Кайда адашты ул, кайда калды,
Ничек кайтарырга соң борылып.

Кайтыр идем кабат яшьлегемә

Кодрәтемнән килсә әгәр дә.
Йөрер идем иркен болыннарда,
Җиләк җыеп ямьле Сәйдәлдә.

Кама өсләреннән ак параход
Кычкыртып ла уза кебектер.
Юк ла, бу тик хыял гына.
Ул тарафка юллар өзектер.

Еллар уза тора, гомер уза,
Чәчләргә дә күптән чал керде.
Мин йөрегән яшьлек сукмаклары
Тапталдылар инде, күмелде.

Үзгәрде шул дөнья, бик үзгәрде,
Борып булмый инде кирегә.
Мин хыялый уйларымда калам,
Ә син ашкынма, йөрәк, тилермә.

## Туган нигез

Туган нигезем, туган бусага,
Йөрәккә җылы сүз, якын да.
Һич аңлата алмаслык мәгънә ята
Шушы газиз сүзләр уртасында.

Уйлап кара, шушы нигезләрдә
Кемнәр туган, кемнәр яшәгән.
Еллар белән күпме гомер узган,
Бер-бер артлы буын алышынган.

Торган нигез ташы нык булганга
Узылган бит күпме язмыш анда.
Саклый нигез ерак истәлекләр
Тапшырырга яңа буыннарга.



## РӘМЗИЯ ГӘРӘЙ КЫЗЫ МӨХЕТДИНОВА

Мөхетдинова Рәмзия Бондюг районы Бәзәкә авылында 1946 елда колхозчы гаиләсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлап, Алабуга пединститутына укырга керә . Укытучы буларак, тәүге адымнарын Иске Юраш мәктәбендә ясый.

Рәмзия Мөхетдинова 1973 елдан 2005 кадәр Бәзәкә мәктәбендә рус теле һәм татар теле укыта һәм, бер үк вакытта, 20 ел өлкән вожатый булып эшли. Эшләгән еллар дәвамында хисапсыз ярыш, бәйрәм, бәйге, концерт, конкурслар оештыра , үзе дә аларда даими катнаша. Менә шундый чараларда теманы ачу һәм бизәү, кичәнең эчтәлеген баету өчен шигырьләр иҗат итәргә туры килә аңа. Каләм тибрәтү шулай башлана.

## “Рәхәт” тормыш килде.

( 90нчы елларда кибет киштәләре бушап калган чакта язылды)

“Рәхәт яшибез” сүзләре
Җимерелде, ишелде.

Аяктагы соңгы носки да
Бүген кичкә тишелде.

100гр. конфетны әни
Ничекләр безгә бүләр?
Бәләкәй чакта кесәмә
Тутырасым калган, җүләр.

Бала юләрлегем белән
Запаслар җыя алмадым.
Айлык нормамны ашадым,
Алай да туя алмадым.

Сок та эчәсем килә,
Торт та ашыйсым килә.
Шулар искә төшкән саен
Әллә нишләп кикертә.

Белми дисеңме әллә,
Күрми дисеңме әллә.
Әллә кайчангы конфетның
Тәме авызда әле дә.

Инде ниләр эшләргә?
Җитми терсәк тешләргә.
Бераз акча юнәтергә
Керимме әллә эшләргә.

Алай итә, болай итә,
Әни белми нишләргә.
Сиңа, ди, бәйрәмгә күлмәкне
Гәҗиттән тегимме әллә.

Ачуланмагыз, апалар,
Орышмагыз, абыйлар.
Шундый “рәхәт” тормыштан
Сезгә дәшә сабыйлар.

## Сөмбелә бәйрәменнән чүп үләннәр җыры.

Чүп үләннәр дигән булып,
Бәйрәмгә кертми ятасыз.
Сөмбеләне генә мактап,
Безне бетереп атасыз.

Тыңлагыз әле безне дә:
Сарут белән билчәнне.
Дуслашырга килдек сезгә,
Сөймәсәгез хезмәтне.

Үтергически гашыйк без
Начар эшкәрткән кырга.
Төкереп тә бирмибез без.
Корылыкка, яңгырга.

Эш сөймәсне яратабыз,
Хөрмәтлибез ялкауны.

Күрә алмыйбыз агрономны,
“Хезмәт” атлы батырны.

Кырга барып йөрмәгез сез,
Киләдер ич йокыгыз.
Без булырбыз анда хуҗа,
“Мул” булыр уңышыгыз.

## Әбиләр чуагы

(“ Алтын көз” бәйрәменнән)

Көз хакимлек итә табигатьтә:
Илаһи мизгеле – Әбиләр чуагы.
Алтын көзнең тылсымлы, сихри дә
Бәллүрдәй чиста һәм аяз чагы.

Сүзләр генә җитми сүрәтләргә
Матурлыгын шулчак көзләрнең.
Җанга рәхәт, якты хисләрдән.
Наз, сөю бөркегән чагы күзләрнең.

(Әбиләр чуагы сүзләре):
“Ак хыяллар, ак өметләр булып
Сарыламын назлы йөзегезгә.
Сез дә шундый ак юллар калдырып,
Керегезче гомер көзегезгә.”

Әбиләр чуагы, Әбиләр чуагы,
Күңелләргә үтә синең рәхәт.
Әй, табигать! Юмарт бүләгеңә
Без юллыйбыз сиңа чиксез рәхмәт.

## Безнең гаилә

(Пар балдаклар бәйгесе өчен визит карточка)

Мөхетдиновлар гаиләсе без,
Таныш булаек, дуслар.
Иң элек һәрбарчагызга
Теләп китик уңышлар.

Мин – Рафис , ә мин – Рәмзия,
Мин – нефтьче, мин – укытучы.
- Ул минем гомер юлдашым,
- Ул парым, ярым, булышчым.

Таныштырды, кавыштырды
Безне Юраш авылы юллары.
Сагындырып төшкә керә
Кабатланмас яшьлек еллары.

Бергәләшеп, ярдәмләшеп,
Өч бала үстердек без.
Тормыш куйган киртәләрне
Икәүләшеп җиңдек без.

Икебез дә сәхнә яраттык,

Вакыт юк дип тормадык.
Халык күңеленә керерлек,
Байтак рольләр уйнадык.

Менә шундый гаилә без –
Кыска гына әйткәндә.
Бүген дә сезнең алда без,
“Пар балдаклар” бәйгесендә.

“Без җиңәбез!” – дип, әйтмибез,
Кемдер җиңәргә тиеш.
Һәр тырышлык нәтиҗәдә
Бирәчәк татлы җимеш.

## Визитная карточка на конкурс “Учитель года”

Родилась я в год «Собаки»,
Но никогда не лаю на людей.
Наоборот, люблю знакомства,
И имею множество друзей.

Благоприятно влияет
Планета Юпитер на « Стрельца».
Во мне все горит: кровь и сердце,
Я – Молния, Огонь и Зарница.

По темпераменту я – Холерик,
Им был и Пушкин, чудотворец.
Его называли – гений, красавец,
А меня же просто – «молодец».

Беспокойна я, непоседа,
Делать что-то все стараюсь.
Не угомонюсь, не успокоюсь,
Пока своего я не добьюсь.

Уже давно, со школьной парты
Я в окружении детей.
Думаю, что нашла и ключик
К юным сердцам своих друзей.

Увлеклась как-то однажды
Историей родного края.
Дорога мне земля родная
И не нужно никакого рая.

Поиск - находка, версия - разгадка –
Основа основ нашей работы.
Ступишь на путь краеведа –
Назад не жди уж поворота.

Не горюю, что виски седые –
Они же у меня от мудрости.
Не беда, что у глаз морщинки –

Это от постоянной улыбчивости.

Не жалею, что этой дорогой
До конца мне придется идти.
Старость меня дома не застанет –
Я в дороге, я в пути.

**Бөркет йөрәкле былбыл.**
(Сөекле җырчыбыз Вафирә Гыйззәтуллинаның
70 еллык юбилеена багышлана)

Былбыл – талда,
Ә Вафирә – залда
Өзеп-өзеп сайрыйлар.
Моңлы тавыш,
Татлы сагыш
Күңелләрне айкыйлар.

Ирек даулап,
Тел, милләтне яклап
Булдың гүя җил-давыл.
"Ком бураны"ң
Яуга чакыру булды,
Бөркет йөрәкле былбыл.

Очтың, аккош,
Алда, диеп, ак кыш.
Җан авазың кочты күк.
Чыкмас истән,
Төшмәс телдән –
Бондюг кызы Зиләйлүк.

**Гомер мизгелләре бүләк итүче...**
(Авылдашыбыз, танылган профессор-онколог
Рифкать Таҗиевка 75 яшь тулу уңаеннан)

Гади, ягымлы, вожданлы –
Болар сезгә хас сыйфатлар.
Нәкъ менә шундый буладыр
Җирдә иманлы затлар.

Ал да гөл генә булмыйдыр
Башкарган һәр эшегез дә.
Үртәләсез, борчыласыз, гүя
Яртылаш үләсез үзегез дә.

Ә бит сез дә адәм баласы,
Түгел Аллаһының илчесе.
Гомерне бирә бер Ходай,
Ә Сез гомер мизгелләрен
бүләк итүче.

Туар таңнар әле озак еллар
Бәхет-сәгадәт китерсен.
Бәрәкәтле картлык Сезне
Саулык белән сөендерсен.

**Сиңа дәшәбез, ФАН чишмә!**
(Тәкәш авылының Фан чишмәсен
яңартып ачу тантанасына багышланган шигырьләр.)

Әй, саф сулы изге Фан чишмәсе,
Барыбыз да бүген сиңа килдек.
Башны иеп, тезне чүгеп алларыңа,
Сихәтле суларың авыз иттек.

Талларыңда сайрый былбыл кош,
Җаннарга күчә моңнары.
Җир куенынннан аккан чишмәдә
Гүя чыңлый чулпы чыңнары.

Урак урган монда әби-апалар,
Ир-егетләр печән чапканнар.
Көмештәй салкын суыңны эчеп,
Тәннәренә көч-җегәрлек алганнар.

Әй, Чишмәкәй! Саф су тамчыларың
Туган җирнең, гүя, зәңгәр күзләре.
ФАН чишмәсе, җавап бирче безгә,
Бардыр синең дә әйтер сүзләрең.

**ФАН чишмә авазы**

Ата-бабалар чорыннан аккан
Изге, шифалы ФАН чишмә мин.
Суларым эчкән бик күпләрнең
Дәва тапканнарын беләмен.

Баш очымда үскән өч талда
Сайрый кошлар, тынмый җырлары.
Челтерәвемдә ишетелә сыман
Әби – бабайларның чулпы,
чалгы чыңнары.

Олы бәйрәм ясыйсыз биредә,
Мин дә бүген кабат тугандай булдым.
Мине ихлас кайгыртуың өчен
Мең рәхмәт сиңа, Минегали улым.

Үз изгелекләрең үзеңә кайтсын,
Сау-сәләмәт, исән бул, авырма.
Раббым, шундый ярдәмчел улыңны
Әҗер савапларыңнан калдырма.

Сез килегез миңа, сулар эчегез,
Җан-тәннәрегезгә сихәт алыгыз.
Әмма бер шарт: бу байлыкны,
хозурлыкны
Күз карагыздай саклагыз.

- Аңла , Кеше!
Җир-сулар Аллаһ бүләге!

Син онытма моны, татарым.
Җир-Анабыз исән-имин булганда,
Мин агармын да агармын,
-Агармын мин агармын,
- Агармын да агармын...



## КАМИЛ ГЫЙЛЬМУЛЛА УЛЫ ГЫЙЛЬМУЛЛИН
## ( 1929-2017 )

1929 елда Бондюг районы Камай авылында крестьян гаиләсендә туа. Җидееллык мәктәпне, 1943 елны, гел яхшы билгеләренә генә тәмамлап, Удмуртия республикасы Әсән зооветеринария техникумына укырга керә. Бу уку йортын тәмамлагач, районыбызның 8 авылында үз белгечлеге буенча эшли. Әмма югары белем алу теләге күңеленнән һич китми һәм ул Алабуга укытучылар институтына укырга керә. Укуын тәмамлагач, Иске Бигәш авылының җидееллык мәктәбендә биология, химия, география укытучысы булып эшли. 1960 еллар башында Бәзәкә мәктәбенә директор итеп билгеләнә. Яшь белгеч һәм аның гаиләсе авылны, аның халкын, мәктәп коллективын үз итәләр, яраталар. Камил Гыйльмуллин җор телле, тапкыр сүзле, көчле оештыру сәләтенә ия шәхес була. Ул шигырьләр яза, укучылар белән шау-гөр килеп концерт-кичәләр оештыра. Аның шигырьләре районыбыз, Чаллы, Түбән Кама, республика газета-журналларында басылдылар. Бәзәкәдән күчеп китсәләр дә, ул безнең авыл белән һәрчак элемтәдә булды.Ул иҗат иткән бик күп шигырьләр арасында авылыбызга багышланганы да бар.

### БӘЗӘКӘ БОЛЫННАРЫ
(сагыну)

Кама буена җәелгән
Бәзәкә болыннары.
Утлап йөри акрын гына
Атлары, колыннары.

Бу болында кемнәр генә
Мәхәббәтен тапмаган?
Ничә шагыйрь, хыялланып,
Шигырь язып ятмаган?

Ул бөрлегән, күрче, әнә,
Рәхәтлән, җый, иренмә.
Юк, иннегең кирәк түгел
Тиеп китсә иренеңә...

Кызлар ирене кызыллыгы –
Гөлҗимешләр, баланнар.
Әрәмәлек арасында
Печән чапкан аланнар.

Тал чыбыкларын җыясың
Кәрзиннәр үрергә дип.
Гүзәллеген бу болынның
Бер тапкыр күрергә дип.

Күрше авылның яшьләре
Ел да киләләр монда.
Балыклы Пинәрә күлен
Мактап туймаслык җырда.

Шонкар карт, Кәрсә Миннәхмәт
Әгәр пешерсә уха,
Телеңне йотып ашыйсың,
Бүтән сыең – чепуха!

Бу болыннар юк шул инде.
Сагындым. Искә төште.
Бетон каеш буып алгач,
Чал Кама – диңгез төсле.

Моңланып оча акчарлак,
Дулкынлана су өсте.

# Яшь талантлар



Мәктәптә укыганда ук алар, күңелләренә илһам килгән мәлдә, кулларына каләм алып, кечкенә әкиятләр, хикәяләр, шигырьләр яза башлаган укучыларыбыз. Менә алар: Гыймадиев Марат, Хикматова Ландыш, Шиабиева Диана, Ефимова Эльвина, Гыйззәтуллина Миләүшә.

Кече яшьтән үк күңел җылысын, эчкерсез, самими хисләрен ак кәгазьгә төшерү, башкаларга җиткерергә тырышу – бу инде дөньяның матурлыгын, туган якның гүзәллеген башка күзлектән күрү, аны ярату, һәр җан иясенә бәхет, мәрхәмәт һәм мәхәббәт бүләк итү дигән сүз.

Әйдәгез, яшьләргә сүз бирик.

## Марат Гыймадиев

### ТУГАН АВЫЛЫМ - БӘЗӘКӘ

Бәзәкә буйлап атлыйм мин,
Уйлыйм авылым турында.
Бәзәкә - туган авылым,
Сагынып кайтам мин монда.

Туган авылым Бәзәкәгә
Нинди матур төс кергән.
Ничә еллар үтте инде,
Бәзәкә нык үзгәргән.

Яңа йортлар балкый бездә,
Бөтен җиргә нур сибә.

Күгәрченнәр гөрли-гөрли
Очалар күгебездә.

Шундый ук матур авыл
Булмастыр бүтән җирдә,
Тик Бәзәкәмдә генә
Күңелгә нурлар иңә.

**АВЫЛЫБЫЗ МӘЧЕТЕ**

Мәчете булган авылга
Һәрвакыт нурлар иңә.
Бәла-каза читләп уза,
Авырлыклар чигенә.

Ураза, Корбан гаете
Бик зурлап уздырыла.
Түбән очтагы мәчеткә
Бик күп халык җыела.

Һәркөн саен манарадан
Азан тавышы килә.
Озак еллар яңгырасын
Бу азан азат илдә.

**АТКА МӘДХИЯ**

Авыр булды сугыш, күпләр үлде,
Ятып калды дуслар ятларда.
Курыкмыйча, горур барган өчен,
Рәхмәт әйтәм хәзер атларга.

Рәхмәт атка, чөнки ул булмаса,
Җиңмәс идек без бу сугышта.
Үрнәк алып аттан, тырыш, көчле булып
Алга барыйк шушы язмышта!

**ИЗГЕ ТЕЛ**

И матур тел, и изге тел,
Син минем туган телем.
Онытмамын беркайчан да -
Син бирдең миңа белем.
И мөкатдәс анам теле,
Синең ярдәмең белән
Булырмын шагыйрь, галим.
Үз телемне ташламам, дип
Әйтәмен: "Амин, амин".

**СВЕТОФОР**

Кызыл, сары, яшел төсне
Белү кирәк һәркемгә.
Юлда йөрү нормасына
Әйләнсен ул һәр көнгә.
Игенче дә, терлекче дә

Кагыйдәне бозмасын.
Укучы да, спортчы да
Аны урап узмасын.
Кызыл төсе - туктата,
Сары төсе - кисәтә,
Ә яшеле балаларга
Чыгу юлын күрсәтә.
Светофор булмаган җирдә
Бер дә аптырап калма:
Як-ягыңа карангала,
Зебралы юлдан атла.
Юлда йөрү кагыйдәсен
Һәркемгә белү зарур.
Әгәр аларны үтәсәң,
Яшәвең булыр матур.
Юлда йөргән бер кеше дә
Онытылып китмәсен,
Кемнеңдер бер ялгышуы
Фаҗигагә илтмәсен.

## Ландыш Хикмәтова.

**ГӨЛЛӘР**

Тәрәз төбендә гөл үсә,
Яфраклары яшәреп.
Җәй җиткәч тә чәчәк ата,
Матур төсләргә кереп.

Һәммәбез дә сокланабыз,
Матурлыгына карап.
Күзләрне һич алып булмый
Чәчәкләренә карап.

Матур чәчәк атсын диеп,
Көн дә сулар сибәм мин.
Үземнең дә чәчәк кебек
Исемем Ландыш минем.

**КЫШ**

Кыш килгән безгә кунакка
Ак алъяпкычы белән.
Суык көннәр булыр әле
Карлы бураннар белән.

Агачларга бәсләр кунган
Ап-ак бизәкләре белән.
Балалар да сөенәләр
Кышның килүе белән.

Яңа ел бәйрәме җитте,
Матур чыршы куйдылар.
Кыш бабайһәм Кар кызы да
Бүләк алып килделәр.

**ИЗГЕ УРЫН**

Манаралар ауган элек
Явыз кешеләр кулыннан.
Яздырырга теләгәннәр
Дин һәм Ислам юлыннан.

Изге урын - Ходай йорты,
Өр-яңа мәчетебез.
Азан тавышларын тыңлап
Сафлана күңелебез.

## Шиабиева Диана

**Урман кызы.**
Уйлап кара әле син, сабый бала,
Күзге урманны яхшылап кара:
Яңгырлар ява, җил яфрак коя,-
Бу могҗизаны кем эшли ала?

Белмәсәң, менә, яхшылап тыңла:
Сары, кызыл, алтын күлмәк кигән
Чибәр, гүзәл, бик матур да –
Ул бай Урман кызы була.

Сез тагын артык уйлый күрмәгез,
Урман алтын белән тулган, димәгез.
Бу бай дигәнем – түгел алтыннар,
Ә яфрак, җимеш, гөмбә, җиләкләр.

## Бөтерелә-бөтерелә карлар ява.

Бөтерелә-бөтерелә карлар ява
Салкын көнендә кышның.
Көннәр дә бит кеше кебек:
Җылы, якты, кырыс, салкын.

Җылы көндә, якты көндә
Бик күңелле кешеләргә.
Бигрәк тә саф күңелле
Кешеләрнең йөрәгенә.

Салкын көн дә, кырыс көн дә
Ошамый бит һәр кешегә.
Ошыйдыр ул, ошыйдыр ул
Бәлки кайбер кешеләргә.

## Ефимова Эльвина

### Әнием

Әнием минем бик булган,
Чиста, пөхтә, бик уңган.
Белем бирә ул көн саен –

Арып кайта шунлыктан.

Әни безне бик ярата,
Сөя, иркәли белә.
Бик тә яратабыз аны
Шундый булганга күрә.

Онытып та торам икән –
Сеңлем дә бар бит әле.
“Ләйсән” бакчасына йөри –
Аңа биш кенә әле.

### Яз җитә

Җиргә балкып, елмаеп
Кояш нурларын сибә.
Язның җитүен сизенеп,
Сыерчыклар да килә.

Яз җитүенә җирдә
Балалар да сөенде.
Сыерчыклар килүенә
Оялар да эленде.

Елгадан бозлар китүен
Ишетте умырзая.
Сөенеченнән яз гөле
Бар дөньяга елмая.

## Миләүшә Гыйззәтуллина

### ТУГАН АВЫЛЫМ - ТУГАН ЙОРТЫМ

Мин радио тыңлыйм. Бүлмә эченә талгын гына моң җәелә:

Туган авылым урамын
Кабат-кабат урадым.
Баш очымда кош сайрады,
Бәхетемә юрадым.

Җыр агыла да агыла. Моңы күңелгә якын, сүзләре җанга ятышлы, сагышлы - якты көе йөрәкне назлый, иркәли. Күңелемә уй килде: чыннан да, үзенең туган авылын, туган җирен яратмаган кеше бармы икән ул дөньяда?!

Туган авылым! Никадәр кадерле син минем өчен! Кая гына барсам да, туган авылым күз алдымнан китми. Кояшлы иртәсе, кошлар сайравы, матур табигате, Пинәрә буйлары яңадан күз алдыма килеп баса. Туган авылын яратмаган, чит җирләрдә яшәп тә, аны сагынып кайтмаган кеше юктыр, минемчә. Шагыйрь әйткәнчә:

Матур булса да торган җир,
Сагындыра туган җир.

Нинди генә чит җирләрдә булсаң да, туган авылың барысыннан да матуррак һәм якынрак күренә. "Шаян" бию ансамбле белән быел мин Болгариягә бару бәхетенә ирештем. Анда узган ярышта иң югары дәрәҗәле урын алуыбызны да мин бары тик туган җиремдәге, туган авылымдагы гүзәллекне, матурлыкны күреп үсүдәндер дип уйлыйм. Һәм, әлбәттә, анда нинди генә чисталык, матурлык, пөхтәлек булмасын, туган авылымны сагынып кайттым. Чөнки туган авыл ул бер генә.

Авылымда үткән балачагым, беренче аяк баскан җирем, укыган мәктәбем... Бу сүзләрдән соң тирән уйга чумасың һәм балачагыңны кабат искә төшерәсең, анда кире кайткандай буласың. Туган авылны мактап телгә алмаган кешене очратканыгыз бармы? Юк. Әйе, туган җир, туган авыл тик матур гына була ала, чөнки анда алтын куллы, кайнар йөрәкле, күркәм табигатьле кешеләр яши.

Туган авылым! Аның табигате гаҗәп матур. Урманы гына да ни тора бит!

Кышын да, җәен дә гел ямь-яшел. Чыршылары, сылу каеннары, төз наратлары булганга шулайдыр. Урманга килеп керү белән әкият дөньясына чумасың һәм сөекле шагыйребез Г. Тукайның шигырь юлларын искә төшерәсең:

Тезелеп киткән гаскәр кеби чыршы, нарат.

Төпләренә ятканым бар хәл җыеп, күккә карап.

Бу шигырь авылыбыз урманына туры килә. Әйтерсең, аңа багышлап язылган.

Чү, каядыр чишмә тавышы ишетелә. Әнә, кайда икән ул! Биек тау башыннан үзенә юл эзләп, челтер-челтер Баллы чишмә ага. Аның саф суы мең төрле авыруга дәва, ди әбиләребез, бабаларыбыз. Юкка гына Баллы чишмә дип атамаганнардыр.

Әйе, авылымның матурлыгына сокланып туймаслык. Минем өчен андагы һәр минут, һәр мизгел кадерле. Мин туган авылым белән горурланам.

Елдан-ел матур табигатьле авыллар саны кими бара. Хәзерге вакытта күп кешеләр, ата-ана, әби-баба нигезен ташлап, шәһәргә юл тоталар. Һәм нигез таркала, урынында шаулап кычыткан үсеп утыра. Ләкин алар, сагынуларына түзә алмыйча, туган авылларына кайталар. Һәм кычыткан үскән нигезләре каршында баш иеп, моңаеп басып торалар. Мондый кешеләрне күргәч, ирексездән күңелгә шигырь юллары килә:

Туган авылым урамын

Соңгы кабат урадым...

Мин туган авылымның андый хәлдә калуын теләмим һәм ул калмас та. Хәзерге вакытта авылыбызда зур төзелешләр бара. Ул елдан-ел матурланыр, яшәрер, яшеллеккә күмелер.